ҺӘРВАКЫТ ЯНӘШӘ

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм итү фондына кем һәм нәрсә өмет итеп килә?

> 3

ВАТАНПӘРВӘР ӘБИЛӘР

Туксанга якынлашучы Рәйсә апа белән Әлфия апа хәрбиләргә киемнәр тегә, оекбашлар бәйли

> 4

ТАТАРЧА ПОСТМОДЕРНИЗМ

Равил Сабыр яңа романы турындагы фикерләре белән уртаклашты

> 6

ХА-ХА-ХАНӘ

Булмас димә, кызык-мызык, фототөрткеләр – монда

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 116–117 (29083–29084) | Сишәмбе | 15 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

ТИМЕРШЫК МӘКТӘБЕ УКЫТУЧЫЛАРЫ:
«БЕЗДӘ НАЧАР УКУЧЫ ЮК»

Үрнәк

Авылда да шәһәрнекеннән калышмыйча менә дигән белем алырга мөмкин. Саба районының Тимершык мәктәбен быел алты укучы тәмамлаган, шуларның икесе (!) имтиханнарда 100әр балл җыйган. Мондый югары нәтиҗәгә ирешкән Айлия Хаҗиева белән Баязит Дәүләтов икесе дә КФУның юридик факультетына укырга кергән. Авыл мәктәбенең уңыш сере нидә икән?

Айлия Хаҗиева БДИда 291 балл туплаган. Имтиханнарга мәктәп укытучылары белән дә, шулай ук тарих һәм җәмгыять белеменнән онлайн мәктәптә дә шөгыльләнгән. Рус теле сынавына укытучысы Гөлфинә Вәлиева (Айлия рус теленнән 100 балл туплаган) әзерләгән. Ә онлайн укытучылары Санкт-Петербург һәм Төркиядә яши икән. Алар – БДИны үз башыннан кичергән яшь укытучылар. Шуңа күрә имтихан тәртипләрен яхшы беләләр. Укучы өчен монысы да бик мөһим. Һәрхәлдә, Айлия шулай ди. Авыл мәктәбендә һәр укучыга да игътибар җитә дип саный ул. Ни өчен дигәндә, сыйныфларда укучылар саны күп түгел. Шуңа күрә начар уку гөнаһ булачак.

– Укытучыларыбыз бик әйбәт. 11 нче сыйныфка күчкәч, аларга тагын да якынайдык. Укыйсы килү теләге дә артты, – ди Айлия. – Авыл мәктәбендә барлык шартлар да тудырылган. Минемчә, шәһәрнекенә караганда, төрле түгәрәкләргә йөрү мөмкинлеге генә азрак. Әйтик, син бит авылда су тубы (водное поло) белән шөгыльләнә алмыйсың. Бассейн район үзәгендә бар анысы. Тик авылдан көн саен районга йөзәргә барып булмый бит. Менә шул ягы бар.

Айлия әйтүенчә, БДИ кирәк, ул авыл баласына шәһәрнеке белән бер тигез мөмкинлекләр ача. Имтиханны яхшы биреп, илнең төрле вузларына укырга кереп була. «Минем дә Мәскәү, Санкт-Петербургтагы университетларга укырга керү мөмкинлегем бар иде. Тик читкә китәсем килмәде. Үз милләттәшләрем белән татарча сөйләшәсем килә. Рус мохитендә тел барыбер онытыла бит ул. Кыскасы, читкә китсәм, телем, мәдәниятем югалыр дип курыктым», – ди милли җанлы Айлия.

Баязитның уңышлары турында әнисе Рәмзия Дәүләтовадан сораштык. Ул элек Кызыл Мишә мәктәбендә башлангыч сыйныфларны укыткан, хәзер тәрбияче булып эшли икән.

– Улым Тимершык мәктәбенә икенче сыйныфка күчте, – ди Рәмзия Дәүләтова. – Кечкенәдән тарих белән кызыксынды. Беренче дәрестә үк тарих укытучысы Зөлфия Зарипова (Баязит шул фәннән 100 балл җыйган) улымның фәнне яхшы белүенә шаккаткан. Безнең өйдә һәрвакыт дөнья атласы эленеп торды. Белемен үстерә торган китапларга акча кызганмадык. Улым кирәкле мәгълүматны кечкенәдән тиз генә эләктереп ала иде. Баязит 4–11 сыйныфка кадәр барлыгы 90 олимпиадада катнашып, җиңүче һәм призер булды. Моңа мәктәп турлары керми. Авыл мәктәбе өчен зур күрсәткеч бит бу!

Сыйныф җитәкчесе, рус теле укытучысы Гөлфинә Вәлиева белдергәнчә, моңа кадәр мәктәптә 100 балл җыючы булмаган. Югары баллга ирешүчеләр һәр елны бар анысы.

– Безнең мәктәп өчен бик зур горурлык инде бу. Быел 100 балл туплаган ике укучы да тырыш, максатчан, – дип мактады ул укучыларын.

Узган уку елында Тимершык мәктәбендә 174 укучы белем алган. Биредә Кызыл Мишә, Көек, Миңгәр авылларыннан килеп укучылар да бар. Быел 1 нче сыйныфка 20 бала укырга керергә җыена. Чыгарылыш укучыларының барысы да югары уку йортларына укырга кергән.

Директорның укыту эшләре буенча урынбасары Олеся Раупова әйтүенчә, уңышка ирешүнең сере юк. Укытучылар тырышып укыта, укучылар тырышып белем ала. Бар хикмәт шунда гына. Мәктәп заманча җиһазлар, такталар белән җиһазландырылган. Шәһәр мәктәбеннән бер ягы белән дә аерылмый. Семинарга килүчеләр дә биредәге шартларга шакката икән.

Мәктәптә укытучыларга кытлык юк. Коллективтагы 28 укытучының берсе генә – пенсия яшендә. 10 яшь укытучылары бар. Иң яше Алисә Мусинага – 22 яшь. Ул ике ел элек башлангыч сыйныфларны укыта башлаган. Мәктәпне тәмамлаган укучылар, педагогик белем алып, шушында укытырга кайта. Шуңа күрә мөгаллимнәрне читтән эзләмиләр. Үзең тәрбияләсәң, анысы да була, димәк.

– Репетиторга йөрүчеләр юк. Укытучылар дәрестән соң атнага ике мәртәбә БДИга әзерлек буенча өстәмә шөгыльләнә. Дөрес, укытучы гына әзерләп бетерә алмый. Балаларның үзләренең дә тырышлыгы кирәк. 100 балл туплаган Айлия белән Баязит кечкенәдән үк олимпиадаларда катнашып, җиңүләр яулады. Алардан БДИда югары нәтиҗә көткән идек, – ди Олеся Раупова. – Без сыйфат дип тырышабыз. Ялган «бишле»ләр белән кызыктыру ягында түгелбез. Билгенең начарын да, яхшысын да куябыз. Бездә начар укучылар юк, ялкаураклар гына бар. Әмма бер-берсеннән күреп, алар да ярышып укый башлый. Башлангычтан ук, уку мөһим, дип тәрбиялибез. Шуңа күрә нәтиҗәләребез дә сөенерлек.

Төзелә һәм төзекләндерелә

Күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү программасы 90 процентка үтәлгән. Бу хакта Татарстан төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов хәбәр итте. 465 күпфатирлы йортта эш дәвам итә. 261 объектта эшләр тулысынча тәмамланган.

Министр урынбасары Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә төзелеш эшләренә бәйле башка мәгълүмат белән дә таныштырды. Әйтик, 43 мәктәптә ремонт буенча эшләр үтәлеше 91 процентны тәшкил итә. Подрядчылар 36 объектта эшләрне дәвам иттерә. 7 балалар бакчасында эшләр 86 процентка башкарылган. Мәктәпләрдәге азык-төлек блокларын ремонтлау программасы кысасында 143 объект буенча эшләр төгәлләнеп килә. 4 урта һөнәри белем бирү оешмасының тулай торагында да төзекләндерү эшләре 88 процентка башкарылган.

Сәламәтлек саклау тармагында өч программа кысасында 149 объект яңартыла. Ниятләнгән эшләрнең 96 проценты инде үтәлгән.

44 мәдәният объектын төзекләндерү бара, шуларның 34е – авыл мәдәният йортлары.

Бурычың булса, түләттерәләр

9,6 млрд сум! Татарстанның суд приставлары бу елның 7 аенда әҗәтле кешеләрдән әнә шулкадәр күләмдә бурыч түләттергән. Былтыргы күрсәткечтән бер миллиард сумга күбрәк бу, дип хәбәр итә Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча баш идарәсе.

Идарә белгечләре әйтүенчә, әҗәтләме-юкмы икәнне белү өчен, суд приставларының рәсми сайтындагы махсус бүлеккә («Банк данных исполнительных производств») кереп карарга мөмкин. Сүз уңаеннан, быел әлеге бүлеккә 277,1 мең тапкыр кергәннәр.

Бурычларны түләттерүгә килгәндә, суд приставлары 2023 елның беренче яртыеллыгында 8,2 млрд сум күләмдә әҗәт түләттерә алган. Суд приставлары бурычлыларның мөлкәтенә арест та сала. Бу җәһәттән 7 меңләп акт теркәлгән. Арест салынган милекнең гомуми хакы 3,8 млрд сумны тәшкил итә.

Моннан тыш торак-коммуналь хезмәтләр буенча әҗәте булганнардан 375,5 млн сум акча түләттергәннәр. Күпчелек очракта андыйларның шәхси милкен кулга алалар икән.

Ярминкәгә килегез!

Тиздән Казанда традицион авыл хуҗалыгы ярминкәсе башланачак. Аның беренчесе 9 сентябрьдә үтәчәк.

Сәүдә 23 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк. Хәзерге вакытта ярминкә узачак мәйданчыклар исемлеге әзерләнә. Товар җитештерүчеләрне җәлеп итү һәм мәйданчыкларда җәмәгать тәртибен саклау өчен җаваплы итеп Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы билгеләнгән. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе белгечләре исә санитар кагыйдәләрнең үтәлешен тикшереп торачак.

Искәртеп үтик: 2022 елда мондый ярминкәләрдә 2,1 миллиард сумлык товар сатылган иде. Шулар арасында 2,6 мең тоннадан артык ит, 360 тонна сөт, 3,5 миллион йомырка, 880 тонна он һәм 18,8 мең яшелчә.

Тизлек фаҗигагә китерә

Ел башыннан Татарстанда мотоцикллар катнашында аварияләр күрсәткече сизелерлек арткан. Былтыр республика буенча мондый төр юл һәлакәтләре 64 булса, быел ике мәртәбә күбрәк, ягъни 128гә җиткән. Иң аянычы – юл фаҗигасендә 8 кешенең гомере өзелгән, 100дән артык зыян күрүче бар.

Аварияләр санының артуына берничә сәбәп бар, ди белгечләр. Шуларның берсе – мотосезонның иртәрәк башлануы һәм Кытайдан кайтарылган җиңел мотоциклларның күплеге.

ЮХИДИ идарәсе мәгълүматларына караганда, Казанда мотоцикллар катнашында 43 авария булган. Шуларда ике кеше үлгән, 46 кеше зыян күргән. Аварияләргә китергән сәбәпләр рәтендә тизлекне арттыру, транспортны йөртү кагыйдәләрен санга сукмау кебекләре бар. Бу елның җиде аенда хокук сакчылары административ җаваплылыкка 670ләп мотоцикл йөртүчесен җәлеп иткән. Шуларның 133е тынлыкны бозган.

Эшлекле очрашу

Яшь элемтәләр

17–21 августта Казанда VI Халыкара яшь дипломатлар форумы узачак. Татарстан башкаласына дөньяның 40ка якын иленнән 100ләп яшь катнашучы килер дип көтелә. Булачак дипломатларны, халыкара мөнәсәбәтләр буенча белгечләрне җыячак чараның үзенчәлекләре нидә?

tatarstan.ru

Катнашучылар. Форум Казанда икенче мәртәбә үтәчәк. Узган елгы форумга 50 илдән 129 делегат җыелган иде. Россия Тышкы эшләр министрлыгының Яшь дипломатлар советы рәисе Константин Колпаков ТАСС агентлыгында узган матбугат очрашуында быелгы форумның катнашучылары турында сөйләде.

– Әлеге чарада быел да Россия белән дустанә мөнәсәбәттә булган илләрдән яшьләр катнашачак. Узган елдан аермалы буларак, Кытай Халык Республикасыннан да катнашучылар киләчәк. Алар Халыкара яшь дипломатлар ассоциациясенә керү турындагы ниятләрен дә җиткерде. Моннан тыш, Африка илләреннән зур делегация килер дип көтелә. Латин Америкасы илләре дә зур кызыксыну белдерде. Һәм, әлбәттә, Беларусь, Кыргызстан, Казахстан, Әрмәнстан кебек дәүләтләрдән дә яшь дипломатлар катнашачак, – диде ул.

Гомумән алганда, катнашучыларның саны узган елгыдан ким булмас, дип өметләнә оештыручылар.

Нәрсә турында сөйләшәчәкләр? Яшь дипломатлар форумының төп темасы – күпполюслы яңа дөнья дипломатиясе. Татарстанның яшьләр эшләре министры Ринат Садыйков вәгъдә итүенчә, яшьләрне эшлекле фикер алышулар, очрашуларга бай булган бай программа көтә.

– Татарстан халыкара хезмәттәшлек мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Бездә уза торган төрле дәрәҗәдәге халыкара чаралар – моңа ачык мисал. Әлеге форум исә аралашу, тәҗрибә уртаклашу өчен уникаль мәйданчык булачак, – диде ул.

Безнең яшьләр. Ринат Садыйков республикадагы яшьләр сәясәтенең дә халыкара мөнәсәбәтләр мәсьәләсенә аерым игътибар бирүен әйтте. Аның сүзләрен Яшьләр дипломатиясе академиясе рәисе Дилбәр Садыйкова да куәтләде.

– Мондый чаралар уздыру тенденциясенең саклануы зур әһәмияткә ия. Хәтта халыкара мөнәсәбәтләр буенча укымый торган яшьләр өчен дә кызыклы ул. Узган елгы форумны оештыруда катнашкан яшьләр дә хәзерге вакытта төрле илләрнең Казандагы генераль консуллыкларында яки башка илләрдәге вәкиллекләрдә эшли. Моннан тыш, без форумда катнашкан чит ил вәкилләре белән төрле юнәлешләрдә ел дәвамында хезмәттәшлек итәбез. Бу шулай ук бик мөһим, – дип сөйләде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сүзгә-сүз

rg.ru

Сергей КРАВЦОВ, Россия мәгърифәт министры:

Укытучыдан бик күп нәрсә тора, шул исәптән, илнең киләчәге дә. Бүген Җир шарында укытучының иң төп һөнәр икәнен аңлау барлыкка килде. «Мәгариф турында»гы законнан «хезмәт күрсәтү» дигән төшенчә алынды. Бу бик мөһим.

(Казанда яшь укытучыларны һөнәргә багышлау чарасында әйткән сүзләре)

БЕЛЕМ КӨНЕНӘ ӘЗЕРЛЕК

«Чек Индекс» хезмәте ачыклаганча, баланы яңа уку елына әзерләү уртача 9,5 мең сумга төшәчәк. Бу суммага беренче сыйныф укучысы минимумы керә: пенал, көндәлек, карандаш, каләм, дәфтәрләр, мәктәп формасы һәм аяк киеме. Башка өстәмәләр белән баланы мәктәпкә әзерләү 22 мең сумга җитәргә мөмкин.

Уртача чектагы кайбер кирәк-яракларга бәя **27 процентка** арткан.

Мәктәп формасына **2915 сумга** күбрәк акча сарыф итәләр.

Канцеляриягә киткән уртача чыгымнар >> **1260 сум.**

55–60% сатып алулар онлайн башкарылган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

НАЧАР КЕШЕЛӘР НАЧАР НӘРСӘЛӘР КЫЛА

Дөнья икътисадында түбәнгә таба авышу дәвам итә. Бер генә илдә дә алгарыш һәм югарыга таба хәрәкәт сизелми. Хәл икътисадта гына түгел, табигый стихияләр нәтиҗәсендә килеп чыккан катастрофалар саны арту сәбәпле, тормышның авыраюы рәвешендә дә начарая. Тайфуннар, янгыннар, су кризисы… Иранның Тебриз шәһәрендә халык Урмия күле кибүгә каршы протест белән чыкты. Бакуда гыйльми җәмгатьчелек, түгәрәк өстәл янына җыелып, Урмия күлен Иран азәрбайҗаннарны кысып чыгару өчен махсус киптерә, дигән белдерү ясады. Елгалар саегу, күлләр кибү нәтиҗәсендә планетаның берничә төбәгендә дәүләтара конфликтлар оешу куркынычы бар. Американың Гавай штатында урман янгыннары штат тарихындагы иң куркыныч стихияле бәла-каза буларак аталды. Рәсми саннар, үлүчеләр – 93, дип белдерә. Рәсми булмаган чыганаклар фаҗигале үлемнәр 500дән артык, ләкин меңнән азрак, диләр. Үлүчеләрнең күбесе – балалар, әти-әниләре эштә булганлыктан, өйдә калган балаларны эвакуацияли алмаганнар.

Финанслар һәм икътисад өлкәсе дә зур һәлакәткә таба адымнарын тизләтә. Дөнья икътисадының төп 16 тармагының 8ендә табыш кими. Икътисадның түбәнгә тәгәрәвен белгечләр нигездә Кытайдагы хәлләргә бәйлиләр. Күк асты иленнән экспорт кына түгел, аңа читтән килүче товарлар агымы да саега. Кытай импорты июльдә алдагы ел белән чагыштырганда 12,4 процентка кимегән. Чиннар әлегә нефть сатып алуның физик күләмен арттыралар, әмма акчалата күләм кими. Импорт кына түгел, үзләрендә җитештерелгәнне дә кытайлылар көннән-көн азрак сатып ала. Июль аенда яңа төзелгәнне сату, алдагы ел июле белән чагыштырганда, 30 процентка кимегән. Бик зур сан бу, ул үзе артыннан төзелеш материаллары һәм көнкүреш техникасы җитештерүне дә түбәнгә сөйри. Илдә елга якын инде ихтыяҗның кимүе нәтиҗәсендә товарларның бәясе төшү күзәтелә. Риба капиталына корылган икътисад өчен бу шок, катастрофа булып санала.

Чиннар демографик кризис зонасына да барып керде. Быел туучылар саны 7–8 миллионнан артык булмас, диләр. Чагыштырыйк: 2016 елда Кытайда 17,8 миллион бала туган, 2019да – 14,6; 2022дә – 9,5 миллион.

Күк асты илендә хәлләрнең начараюы бар планетага тәэсир итә. Байден тиктомалдан гына Кытайны акрын хәрәкәт итүче бомбага тиңләми. «Кытай – бәладә, – диде ул. – Анда кайбер проблемалар бар һәм бу яхшы түгел, чөнки начар кешеләрнең проблемалары булса, алар начар нәрсәләр кыла».

Россиядә

ӨЧ СЦЕНАРИЙНЫҢ КАЙСЫ?

Россиядә үткән атнада да валюта давылы тынмады. Доллар йөз сумлык чиккә терәлеп калды. Үзәк банк валюта сатып алуны туктатуга карамастан, сумның кызу темплар белән зәгыйфьләнүе дәвам итте. Валюта кризисын без, бәяләр күтәрелеше буларак, ике-өч айдан сизәчәкбез, диләр. Россия нефте түшәм бәяне ватып чыкты чыгуын, әмма дә ләкин илнең финанс хәлен бу бер дә яхшыртмый. «Кара алтын» җирле валюталарга, нигездә, һинд рупиясенә сатыла. Кайбер белгечләр, ирония белән, рупиягә сату пыяла муенсага алыштырудан берни белән дә аерылмый, диләр. Нефть белән яңа базарлар яулау кыен. Пакъстан тәҗрибә рәвешендә берникадәр җир маен бездән сатып алган иде, бензин кудырып карагач, ниятләреннән кире кайтырга булдылар. Россия нефтеннән бензин аз чыга, күбрәк мазут ясала. Гарәп нефте белән чагыштырырлык түгел. Бензинны күбрәк алу өчен, нефть эшкәртү заводларын үзгәртеп корырга кирәк, диләр. Исламабадта алай мәшәкатьләнергә теләмиләр.

Газга базар табу да кыен. Мәскәүдә газны Төрекмән газүткәргече аша Кытайга илтергә теләгән иделәр. Төрекмәннәр кискен каршы чыкты.

Россиянең Үзәк банкы ил икътисадының 2026 елга кадәр үсешенең өч сценариен игълан итте. База сценарие дип аталганы хәлләрнең бүгенгечә үсешен фаразлый. Дөнья икътисадында хәлләр хәзергечә барса, алдагы өч елда санкцияләр сакланачак, чималны чит илләргә глобаль базардагыдан түбәнрәк бәягә сатачакбыз. Ил икътисады 2026 елга 1,5–2,5 процентлык үсеш юлына басачак. Инфляция 2024 ел ахырына Үзәк банк куйган 4 процентлы чиккә әйләнеп кайтачак. Сүз уңаеннан искәртик: инфляциягә бәйле фаразлар бик сирәк очракта гына тормышка аша. Гадәттә көтелгәннән начаррак була.

Икенче сценарийны Үзәк банкта «фрагментлыкның көчәюе» дип атыйлар. Илләр блокларга бүленәчәк, глобальләштерү турында онытачакбыз. Бу очракта санкцияләр көчәер. Экспорттан акча азрак керер, үсеш темплары түбәнәер. Импорттан товар алу да акча булмау сәбәпле кимер. Ил сәнәгате импортны алыштырып бетерә алмас. Инфляция темплары югарырак булачак дигән сүз бу. Төп ставканы да күтәрәчәкләр. Кредитлар кыйммәтләнә, димәк.

Өченче сценарий «хәвефле» дип атала. Бу сценарий тормышка ашса, инфляция темплары 2024 елда ук 11–13 процент булыр, сумның курсы түбәнәер, диләр Үзәк банк белгечләре. Без бүген үк шул чиккә якынаеп киләбез бугай инде. Дүшәмбе иртәсенең беренче хәбәре – биржада доллар йөз сумнан ашып китте.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

КҮРЕРГӘ ҺӘМ КҮРСӘТЕРГӘ

«АРМИЯ-2023» ФОРУМЫНДА ТАТАРСТАН НӘРСӘ БЕЛӘН ШАККАТЫРА?

tatarstan.ru

Коралларның яңа үрнәкләре, махсус хәрби операция зонасында үзләрен яхшы яктан күрсәткән хәрби машиналар. Кубинка шәһәрендә «Армия-2023» форумы ачылды. Чарага 60лап илдән делегатлар җыелган. Хәрби-техник форумда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

«Армия-2023» форумы кысасында үз продукциясен илнең оборона-сәнәгать комплексына кергән 1,5 меңнән артык предприятиесе, шул исәптән Татарстан да тәкъдим итә. Төгәлләштереп әйтсәк, бу – Казан вертолет заводы. Ул республикада ясала торган күпмаксатлы Ми-17 очкычын тәкъдим итә.

Экспозицияләр белән танышу кысасында Татарстан күргәзмәсенә дә игътибар бирелде. Татарстан Рәисе Россиянең оборона министры Сергей Шойгу һәм Хөкүмәт Рәисе урынбасары Денис Мантуровка республика исеменнән тәкъдим ителгән продукция хакында сөйләде. Аерым алганда, бу – «Эйдос» компаниясе товарлары, «Ак барс» суднолар төзү корпорациясе продукциясе һәм макетлары, шулай ук башка төр хәрби техника.

«Ак барс» суднолар төзү корпорациясе генераль директоры Ренат Мистахов сүзләренчә, Татарстан тәкъдим иткән продукциягә Казахстан, Бразилия, Вьетнам, Таиланд вәкилләреннән кызыксыну зур булган.

– Теләсә нинди күргәзмә – үз продукцияңне күрсәтү өчен менә дигән мөмкинлек. Без бер урында тормыйча, гел камилләшәбез, үсәбез, яңа нәрсәләр төзибез. Кызыксыну уятырга, барлык мөмкинлекләребезне күрсәтергә телибез. Чит ил вәкилләренә төрле хезмәтләребезне тәкъдим итәбез, шул исәптән кораблар проектын ясау, җитештерү, – диде ул.

Экспозицияләрдә техниканың **200**ләп төрен, **28** меңнән артык экспонат күрергә мөмкин. Нәтиҗәдә чит ил партнерлары белән килешүләр төзеләчәк. Гомуми сумма – **433** млрд сум.

Владимир ПУТИН, Россия Президенты:
– Халыкара форум дөньяда иминлек һәм тотрыклылык тәэмин итү өчен хезмәттәшлекне ныгытырга мөмкинлек бирәчәк. Форум абруйлы һәм танылган, ул Россиянең дустанә илләр белән мөнәсәбәтләрен үстерүгә җитди өлеш кертте. Партнерларга корал төрләренең заманча үрнәкләрен, шул исәптән идарә итү системасы, разведка, төгәл корал һәм робототехника юнәлешендәгеләрен дә тәкъдим итәбез. Форумда пилотсыз оча торган аппаратларга аерым игътибар биреләчәк. Хәзер бу юнәлеш актив үсештә. Катнашучылар арасында чит ил компанияләрен күрергә дә шатбыз. Узган ел үз продукциясен 32 оешма тәкъдим иткән булса, быел андыйларның саны – 82.

Сергей ШОЙГУ, Россия оборона министры:
– Форум – санкцияләр яратучыларга, хаос тудыручыларга менә дигән җавап. 10 ел эчендә әлеге форум әйдәп баручы мәйданчыкка әйләнде. Хәзерге чынбарлыкта безнең кораллар үзләренең ышанычлы һәм нәтиҗәле булуын күрсәтә. Төрле яклап макталган чит ил техникасының исә бик үк шәп булмавын күрәбез. Россия оборона-сәнәгать комплексы санкция басымы шартларында тиз генә эшкә яраклашып кына калмыйча, аерым юнәлешләрдә үз куәтләрен берничә мәртәбә арттыруга иреште.

Сәламәтлек сагында

Инфекцияләрне ачыклау өчен экспресс-тест, лабораторияләр өчен җиһазлар. «Эйдос» компаниясенең эшчәнлеге бүген шуннан гыйбарәт. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов аларның җитештерү мәйданчыклары белән танышты.

Компания 2012 елдан эшли. «Эйдос»ның төп һәм Россиядәге бердәнбер офисы Казанда урнашкан. Җитештерү дә биредә башкарыла. Компаниянең төп юнәлеше – югары технологияле медицина җиһазларын уйлап табу һәм җитештерү. Моннан тыш компьютердан идарә ителә торган медицина симуляторлары (әйтик, кеше рәвешендәге силикон курчаклар) да эшлиләр.

Моннан тыш төрле йогышлы чирләрне ачыклау өчен экспресс-тест чыгару белән дә шөгыльләнәләр. Әйтик, махсус тестлар респиратор инфекцияләрне, шул исәптән коронавирус, грипп кебек вирусларны ачыклый ала. Компания җитештергән тестларны өй шартларында да, медицина оешмаларында да кулланырга мөмкин.

«Эйдос»ның генераль директоры Ленар Вәлиев әйтүенчә, тестларның кайсылары инде илкүләм теркәлү узган, калганнары клиник тикшерү этабында. «Эйдос» җитештергән тестларның илнең башка төбәкләрендә дә сыналганын әйтте җитәкче.

Санкцияләр урап узды, диләр компаниядәгеләр. Ник дигәндә, җитештерү өчен кирәк булган компонентларның 95 проценты – Россиянеке. Мисал өчен, алдарак телгә алынган симулятор-курчакларга төс бирә торган силикон башкалада җитештерелә. Читтәгегә ихтыяҗ юк, кыскасы.

Компания вәкилләре сүзләренчә, «Эйдос»ның 30–40 процент продукциясе экспортка китә. Димәк, санкцияләргә карамастан, товарны чит илләргә җибәрү дәвам итә, заказлар һәм килешүләр әле дә бар.

Татарстан күчтәнәче

Ярдәм янәшә!

Сигез фура, 150 тоннадан артык йөк. Казаннан Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә чираттагы гуманитар ярдәм китте. Машиналарның берничәсендә яңа уку елына дип җыелган күчтәнәчләр дә бар.

Бу – «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге катнашында җыелган гуманитар колоннаның җиденчесе. Гомумән алганда, Луганск Халык Республикасына 1400 тоннадан артык гуманитар ярдәм җибәрелгән иде. Бу – 97 йөк машинасы дигән сүз.

«Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит!» акциясе кысасында «Бердәм Россия» һәм «Яшь гвардия» төбәк бүлекләре Татарстан карамагында булган шәһәр мәктәпләрендә укучы балалар өчен портфельләр әзерләде. 70ләп кирәк-ярактан торган 2 меңнән артык тупланма дигән сүз бу. Әлеге җыелмага канцелярия товарлары, дәфтәр, хезмәт һәм сынлы сәнгать дәресләре өчен кирәк-яраклар кергән.

Моннан тыш, Луганск Халык Республикасына 100 тонна төзелеш материаллары да җибәрелгән. Кирәк-яраклар белән «Унистрой» компаниясе булышкан.

Гуманитар ярдәм буларак азык-төлек, кием-салым, көнкүреш химиясе дә җыелган. Бу юлы кирәк-яраклар юнәтү эшендә Баулы, Менделеевск, Аксубай, Лениногорск һәм Кайбыч районнары катнашкан.

tatarstan.er.ru

«Бер бала да игътибарсыз калмас!» – ди мәктәп укучыларына кирәк-яракларны туплауда катнашкан волонтер егет-кызлар.

Сак бул!

ЧЫГАСЫҢНЫ УЙЛАП КЕР

«Татар-информ»

Су коенырга баручыларга әнә шулай дип кат-кат әйтсәң дә, комачау итмәс. Әгәр бата калсаң, нишләргә? Ярый ла, коенырга рөхсәт ителгән сулык, янәшәдә коткаручылар булса… Суга батучыга ярдәм күрсәткәндә, язмышны минутлар хәл итә. Беренче минутта суга батучыларның – 90 процентын, 6–7 минуттан соң 1–3 процентын гына коткарып калып була.

Сан

- Коену сезоны башланганнан бирле Татарстанда **49** кеше суга батып үлгән.
- «Коенырга ярамый!» дигән җирдә су керүчеләргә **1000–1500** сум штраф каралган. Җәй башыннан **34** кеше штрафка тартылган инде.
- Суга сапборд һәм кечкенә көймәләрдә кергән очракта да тиешле таләпләрне үтәргә кирәк. Барлык кешеләр дә коткару жилеты киярге тиеш. Әгәр көймәдә йөрүчеләр саклык чараларын үтәми икән, аның хуҗасына **15000–20000** мең сум штраф салына.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсенең су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгы бүлеге җитәкчесе Регина Гаязова: «Суда һәлак булуның төп сәбәбе – рөхсәт ителмәгән урыннарда коену», – дип искәртә.

– Суда күңелсезлекләргә юлыкмас өчен, махсус җиһазландырылган сулыкларда гына коенырга киңәш итәбез. Пляжларның да җиһазландырылганын сайлагыз. Күпләр башта кояш астында озак кызына да аннан суга керә. Су температурасы түбән. Шунлыктан өянәк башланырга мөмкин. Кинәт кенә эсседән салкынга кергәндә хроник авырулар да кузгала, – ди Регина Гаязова. – Исерткеч эчемлекләр кулланмау да мөһим. Күп кенә бәхетсезлек очраклары нәкъ менә суга исерек килеш керүчеләр белән була.

Ел саен бер сүз сөйләнсә дә, кешеләр гомерләрен сакламый. Үзләренеке генә түгел, балаларыныкы өчен борчылмаучы әти-әниләр дә очрый. Казанның Дәрвишләр бистәсендә урнашкан «Комсомольское» күлендә үзләре генә ярның бер ягыннан икенче ягына йөзеп чыгучы балаларны күргән идек. Сөйләштердем дә әле. Иң олысына 13 яшь икән. Ике энесен, күрше малаен ияртеп алып килгән. «Әни белә, сүз әйтми. Без бит көн дә коенабыз», – ди бала.

КИҢӘШЛӘР

1 Батучыны ерактан ук тынычландыра башлагыз. Аңа арткы яктан якынаерга кирәк. Каршысына килсәгез, ул сезгә ябышып, икегез бергә батарга мөмкинсез. Әгәр инде сезне эләктереп өлгерсә, суга чумыгыз. Бу очракта батучы кеше сезне җибәрәчәк. Батучының кулыннан, чәченнән яки култык астыннан эләктереп, ярга чыгарырга кирәк.

2 Ярга чыккач, беренче ярдәм күрсәтелә. Батучы аңында, пульсы канәгатьләнерлек булып, сулыш алса, аны каты коры урынга яткыралар. Баш түбәндә булсын. Өстен салдырып, тәнен ышкырга киңәш ителә. Зыян күрүчегә кайнар эчемлек биреп, җылы одеялга төрергә кирәк. Аңында булмыйча, пульсы һәм сулышы булган очракта башын артка җибәреп, аскы теш казналыгын каерып, башы аска төшеп торырлык итеп яткырырга һәм бармак белән авыз эчен чистартырга, тәнен корытып сөртергә һәм җылытырга кирәк. Аңында булмаган, сулышы сизелмәгән, әмма йөрәге типкән зыян күрүчегә, сулыш юлларын чистарткannan соң, тизрәк ясалма сулыш алдыру шарт. Сулышы һәм йөрәк тибеше булмаганда, ясалма сулыш алдыруны йөрәккә массаж ясау белән аралаштыру мөһим.

3 Бик яхшы йөзә белгән кеше дә батарга мөмкин. Суда янаган куркынычны алдан белеп булмый. Йөзүченең аягына суүсемнәр чорналырга яки көзән җыера башларга мөмкин. Аякка суүсемнәр уралса, урында тыпырчынырга ярамый, болай иткәндә, алар тагын да ныграк уралырга мөмкиннәр. Бу урыннан кинәт кенә этелеп китәргә кирәк. Көзән җыеру да паникага бирелү өчен сәбәп түгел. Бу очракта су астына төшәргә, аякны турайтырга һәм баш бармактан тотып, көчәнеп, табанны үзеңә таба тартырга кирәк. Шуннан соң кеше аяклары белән хәрәкәтләнә һәм ярга йөзеп чыга ала.

4 Йөзүченең чоңгылга эләгү куркынычы бар. Куркырга кирәкми – үпкәләрегезгә мөмкин кадәр күбрәк һава җыегыз да су астына төшегез. Тирәндә су әйләнгән җирдән кисәк кенә этелеп китәргә һәм читкә сикерергә кирәк.

Ә коткаручылар, балаларны үзләрен генә сулыкка җибәрергә ярамый, дип чаң суга. Регина Гаязова сүзләренчә, хәтта су эчендә дә алар ялгыз булырга тиеш түгел.

– Кайберәүләрне кисәтү дә, штраф та куркытмый. Күп кенә сулыклар буена коенырга ярамавы турында язулар урнаштырылды. Тик ярамыйга карамый. Нәкъ шул язу янында рәхәтләнеп су керәләр, – ди җитәкче. – Без һәрвакыт кисәтеп торабыз. Пляжларда коткаручылар суда үзеңне ничек тотарга икәнен аңлаткан күрсәтмәләр дә таратып йөри. Кисәтәләр дә. Коткаручы янәшә булгач, суда батмабыз әле, диючеләр дә бардыр. Тик сезне вакытында күреп өлгермәскә дә мөмкиннәр бит. Коенырга кергәндә, үзеңә ышанырга кирәк. Йөзә беләсең икән, йөз, белмисең икән, сабыр ит. Су ялгышларны кичерми.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СОҢГА КАЛМЫЙЧА

Ватан хакына

«Эшебез күп булачак. Һәм аны иseme түгел, ә нәтиҗәсе булсын өчен башкарырга кирәк», – ди «Ватанны саклаучылар» фондының Татарстандагы филиалы җитәкчесе Гүзәл УДАЧИНА. Аның белән оешмага кемнәр ни өмет итеп килүе һәм аларга нинди ярдәм күрсәтелүе турында сөйләштек.



Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Гүзәл Любисовна, фонд филиалы әле 1 июньдә генә эшли башлады. Күп вакыт узмады, шулай да ниләр эшләргә өлгердегез?

– Безнең фонд – Россиядәге иң яшь федераль структура. 1 июньдә аның филиаллары илнең барлык төбәкләрендә эшли башлады. Төп бурычыбыз – махсус хәрби операция ветераннары һәм анда һәлак булган сугышчыларның якыннарына ярдәм күрсәтү. Әнә шул категориягә кергән кешеләргә адреслы, ягъни һәрберсенә аерым игътибар бирелә. Һәрберсенә аерым социаль координатор билгеләнә. Аларга ярдәм итү өчен махсус программа әзерләнә. Бер тапкыр булыштык та, шуның белән бетте дигән сүз түгел. Авырлыклар килеп чыга икән, без һәрвакыт янәшәдә, элемтәдә торабыз. Үзләре килеп, ярдәм сораганны көтеп утырмыйбыз. Социаль координаторлар, үзләре барып, кешенең хәлен белешә.

Моңа кадәр мондый оешма юк иде. Ә Әфган сугышын кичкән, Чечняда булган егетләрнең, кайткач, нинди авырлыклар аша узганын беләбез. Бу фондны оештырганда монысы да исәпкә алынгандыр дип уйлыйм. Яңа эш. Тиз арада яңа алымнар уйлап табарга, кайчак эш рәвешен үзгәртергә туры килә. Ә командабыз моңа сәләтле. Кешеләргә нәрсә кирәклеген белергә кирәк. Без менә бер нәрсә уйлыйбыз, аларны исә бөтенләй башка нәрсә борчырга мөмкин. Гаиләләр, әйтик, һәлак булган якыннарының онытылмавын тели. Монысы да – безнең бурыч.

:: Күбрәк кемнәр һәм нинди сораулар белән киләләр?

– Төп ике категорияне әйттем инде. Ә эшли башлагач, безгә күбрәк хәзерге вакытта хәрби операциядә катнашучылар, аларның якыннары килгәне ачыкланды. Ялга яки сәламәтлеген ныгытырга кайткан егетләрнең гозерләре бар. Берсен дә кире бормыйбыз. Сораулары да төрле. Тиз арада аларга ярдәм итү чараларын табарга туры килә. Беркем дә 30 көн вакыт бирми. Ялга кайткан егетләрнең ул кадәр вакыты да юк. Әйтик, аларның тиз арада хастаханәгә барып, сәламәтлеген ныгытасы, акча түләүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итәсе бар. Сүз уңаеннан, ветеран булсынмы ул, әллә хәзерге вакытта катнашучымы – Татарстанда аларның барысына да медицина ярдәме күрсәтү җайга салынган.

Хәбәрсез югалган кешеләрнең якыннары да мөрәҗәгать итә. Аларга ярдәм итү алымнарын җайга сала алдык. Хәрби частьлардан белешмә алырга, судка мөрәҗәгать итү өчен документлар әзерләргә кирәк. Балаларын укыту буенча мөрәҗәгать итүчеләр бар. Бу мәсьәләләр хәл ителә. Әле эшли генә башлаган вакытта ветеран таныклыгы алу буенча сораулар күп иде. Бу эш җайга салынгач, андый сораулар кимеде.

Ике айдан аз гына артыграк вакыт эчендә 1400дән артык мөрәҗәгать кабул иттек. Шуларның 1200дән артыгы хәл ителде. Кайберләре буенча бераз сабыр итәргә, әйтик, тиешле карарлар чыкканны көтәргә туры килә. Әмма бу мөрәҗәгатьләр онытылмый. Чөнки социаль координаторлар бу кешеләр белән элемтәдә тора.

:: Башка оешмаларда яклау таба алмыйча, сезгә килүчеләр бармы?

– Игътибар итсәгез, безгә килгән кешеләрнең мөрәҗәгатьләре турында сөйләгәндә, социаль яклау чараларын күрсәтүгә бәйле сорауларны искә алмадым. Ник дигәндә, безнең филиалда бик күп дәүләт оешмаларының вәкилләре эшли. «Бер тәрәзә» алымы ул. Монда Социаль яклау министрлыгы системасына кергән хезмәтләр дә, Социаль фонд та, МФЦ да, юристлар да, башка белгечләр дә бар. Татарстанның Хәрби комиссариаты, Хәрби прокуратура белән эшлибез. Депутатлар да читтә калмый. Алар эшне тизләтергә ярдәм итә.

:: Шулай да төп җаваплылык – социаль координаторларда. Кемнәр ул?

– Татарстанда 40 социаль координатор тупладык. Алар Казанда, 17 район һәм шәһәрдә эшли. Әлегә барысында да юк. Әмма ел ахырына кадәр барлык районнарда булачак. Әйтик, Биектаудагы белгеч Арчага да, Әтнәгә дә йөри. Район башлыкларына рәхмәт, эшнең мөһимлеген аңлыйлар, ярдәм күрсәтәләр. Киләчәкне исәптә тотып эшлибез. Координаторны эшкә алуның төрле шартлары бар. Әйтик, авыр хәлдә калган кешеләр белән эшләү тәҗрибәсе булырга тиеш. Тест узалар. Шул исәптән, психологик тикшерү дә. Башкаларны ишетә белү, ярдәм итү теләге, аның хәленә керә алу кебек сыйфатлар булсын, дибез. Алар ышаныч уятырга тиеш. Якын кешесен югалтканнар белән уртак тел табарга, аларның хәленә керергә кирәк бит. Тест узгач, укырга җибәрәбез. 40 социаль координатор арасында бу эшне якыннан белүчеләр дә бар. Берсенең якын кешесе һәлак булган, тагын бишесенеке хәзерге вакытта фронтта. Психологик ярдәм күрсәтүгә аерым игътибар бирелә. Кемдер баласына әтисенең һәлак булганын ничек әйтергә белми, кемдер психологка мөрәҗәгать итү егет эше түгел дип саный, әмма ул аңа мохтаҗ. Бу эшне артыгын бәйләнмичә генә, йомшак итеп башкарырга кирәк. Гомумән алганда, җыелган командабыз белән бик горурланам.

:: Нинди вакыйгалар истә калды?

– Күптән түгел хәрби операциядә катнашып, яралануы аркасында хезмәттән җибәрелгән бер егет мөрәҗәгать итте. Моннан 8 ай элек ул Мәскәүдәге Бурденко исемендәге хәрби госпитальдә дәваланган. Күпмедер вакыттан соң кабат операция ясарга кирәклеген әйткәннәр. 8 ай узгач барган, әмма хәзер бит инде Кораллы Көчләрдә хезмәт итүче кеше түгел, шуңа күрә госпитальгә эләгә алмаган. Белешә башлагач, әлеге операцияне Татарстанда ясап булмаганы ачыкланды. Бурденко исемендәге госпитальгә мөрәҗәгать иткәч, бер атна эчендә уңай җавап килде һәм егетне операциягә чакырдылар.

Ярдәм итеп кенә калмыйбыз, СВО ветераннарыннан команда туплыйбыз. Әлбәттә, аларга дәваланганда, тернәкләнгәндә, гади тормышка ияләнгәндә, эшкә урнашканда ярдәм кирәк. Әмма бу гына җитми. Иҗтимагый тормышка да кереп китү, аралашу, алар башкарган эшнең әһәмиятен аңлаганнарын белү кирәк. Шуңа күрә балаларга ватанпәрвәрлек тәрбиясен ветераннар аша җиткерү бурычы да бар. Команда туплап, 1 сентябрьдән мәктәпләргә йөрергә җыенабыз. Ник дигәндә, яшьләр белән яшьләр аралашканда, нәтиҗәсе дә яхшырак була.

Кыскасы, эшебез күп булачак һәм аны иseme түгел, ә нәтиҗәсе булсын өчен башкарырга кирәк. Анысы бөтен җәмгыять өчен мөһим.

Әңгәмәдәш – Илнар ХӨСНУЛЛИН

КУЛ ЧАБЫП УТЫРЫП КЫНА БУЛМЫЙ

tatarstan.ru

Мәгариф

Яңа оешкан татар теле укытучылары берләшмәсе ниләр белән шөгыльләнәчәк? Мәктәпләрдә туган тел сәгатьләре, дәреслекләр җитәме? Быел эшчәнлеген туктаткан «Ана теле» онлайн мәктәбен алда ни көтә? Казанның 183 нче гимназиясендә Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин катнашында узган милли мәгарифкә багышланган август киңәшмәсендә шушы һәм башка сорауларга да җавап таптык.

Татарча белем

Узган уку елында республикада 610 татар мәктәбе эшләсә, шуның 106сы – филиал. Татар телендә белем алу күрсәткече – 25, белем һәм тәрбия бирү 51 процентны тәшкил итә. Күпчелек районнарда тәрбия бирү татар телендә оештырылган сыйныфлар саны арту күзәтелә.

Азнакай, Актаныш, Арча, Әтнә, Балтач, Мөслим, Саба, Теләче районнары милли мәгариф үсеше тотрыклы. Ә менә Баулы, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Яңа Чишмә, Питрәч, Спас районнарына эшне көчәйтергә кирәк әле.

Узган уку елында «Туган тел һәм әдәбият» предметлары өлкәсе кысасында укучыларның 63 проценты – татар, 36 проценты – рус телен һәм 1 проценты чуаш, мари, мордва, удмурт, иврит һәм башкорт телләрен өйрәнгән. Татар телен өйрәнү узган елгы дәрәҗәдә сакланган. Укучыларның 61 проценты татар телен республиканың дәүләт теле буларак өйрәнгән.

– Баланың туган тел дәресләрендә нинди тел өйрәнүе әти-әниләрнең гаризаларына бәйле. Мәктәптә милли мохит оештырылган, укучыларның туган тел өйрәнү нәтиҗәләре куанычлы икән – әти-әни гариза да яза, ярдәмен дә күрсәтә, – диде Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова.

– Белемне кызыклы итеп бирү үзебездән тора, – ди Казандагы 184 нче мәктәпнең туган тел укытучысы Алисә Әгъзамова. Яшь укытучы «кроссенс» дигән яңа алым куллана икән. Кроссенс инглиз теленнән «фикерләр киселеше» дип тәрҗемә ителә. Балалар картинадагы рәсемнәр, символларның бер-берсенә бәйләнешен табып, картинадагы төп фикерне әйтергә тиеш. Укытучы әйтүенчә, бу алым укучыларга бик кызык, аларның фикерләү сәләтен үстерергә булыша.

Шартлар бармы?

Федераль дәүләт белем бирү стандартларында да, федераль программаларда да «Туган тел һәм туган телдәге әдәбият» предметлары мәҗбүри фәннәр исемлегенә кертелгән. «Мәгариф турында» Россия кануны нигезендә белем бирү программасы, уку планнары мәктәп тарафыннан эшләнә.

Узган ел татар теле һәм әдәбиятыннан 60 дәреслек федераль исемлеккә кертелгән. 26 дәреслек Россия Мәгариф министрлыгына федераль исемлеккә кертү өчен юлланган.

Бердәм федераль программага күчсәк тә, мәктәпләрдә берни үзгәрми. Татар теле дә, дәреслеге дә шул килеш кала. Министр әнә шулай дип аңлатты.

– Дәреслекләр күп. Департамент тарафыннан: «Ник монысын сатып алдыгыз?», «Ник башкасы белән укытасыз?» – дип бәйләнү юк. Укытучы үзе билгели. Сыйныфта укучылар татарча белә икән, димәк, аларга әдәбиятны югары дәрәҗәдә укытырга кирәк. Әгәр белми икән, аңа Габделҗаббар Кандалыйның аңлашылмый торган әсәрен өйрәтү кирәкми. Гади итеп өйрәтик. Дәреслек юк, монысы юк, дип сәбәп эзләмик. Барысы да җитә. Укытуда рецепт юк. Чирмешәндә ул – бер, Апаста – икенче, Чаллы белән Казанда башка төрле. Рецептны барлыкка китерүче, аны кулланучы – укытучы, – диде Илсур Һадиуллин пленар утырышта.

Кем гаепле?

Министр борчыган проблемаларга үз фикерен белдерде. Ә алар шактый иде.

– Дәресләрне татар телендә укыту буенча Советлар Союзындагыга караганда бермә-бер артка тәгәрәдек. Моның белән килешәм. Шуңа карамастан, без БДИ, башкасы русча дип, артка чигенергә тиеш түгел. Фәннәрне татар телендә укыту булырга тиеш, – диде министр. – Күбрәк методист, мәктәп директорларына мөрәҗәгать итәм. Ел дәвамында мәгариф идарәсе башлыкларына, татар теле һәм әдәбияты дәресләрен кыскартырга ярамый, дип әйтеп киләбез. Татар телен оештыруда бар нәрсә белән килешеп, «ә»гә «җә» дип утырырга кирәкми. Берәр сәгать татар теле һәм әдәбияты укыткан мәктәпләр дә бар. Вазгыятьне мәктәп директоры, татар теле укытучысы, әти-әниләр белеп тора бит. Расписаниедә сәгатьләр – бертөрле, безнең өчен – башка. Без кемне алдыйбыз? Туган тел дәресләре 3–5 сәгатьтән ким булмаска тиеш. Кемгәдер ярарга тырышып, куркып утырмыйк. Кул чабып кына торып булмый бит.

Татарча сөйләшү кимеде, бакчада русча сөйләшәләр, дигән зарларны да министрга еш ишетергә туры килә икән. «Кем гаепле соң? Без өйдә татарча гына сөйләшәбез. Аның каравы балаларның берсе – 3, икенчесе 4 тел белә. Мактанып әйтүем түгел. Бакчага баргач, бала телне онытты, диючеләрне аңламыйм мин. Әлбәттә, бакчаларда бар да ал да гөл түгел. Анда да безнең татарлар эшли. Башка милләт баласы килсә, русчага күчәләр. Моның җаен табып була бит. Чын татар авылларында исә бер русча сөйләшкән кеше юк. Кая гына барсам да, миңа, Мәгариф министрлыгы гаепле, дип сөйләргә тотыналар…. Сөйләмәгез миңа болай дип. Мин бу проблемалар белән яшим, шуңа чумган һәм шуннан чыга да алмам шикелле. Балаларның әти-әниләре дә бар бит. Һаман бакча, мәктәп гаепле. Өйдә сөйләшмәсәң, аңлатмасаң, фикер алышу булмаса, алга китеш булмаячак. Хатаны үзебездән дә эзлик», – диде министр.

Киңәшмәнең төп яңалыгы – Бөтенроссия татар теле укытучылары берләшмәсен булдыру. Аны Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты Рузилә Фәттахова җитәкләячәк. Әлеге оешма туган тел укытучыларының аралашу, тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгы гына түгел, ул аларның хокукларын да якларга булышачак.

Сүз уңаеннан, быел 2013 елдан гамәлдә булган «Ана теле» онлайн мәктәбе эшчәнлеген туктаткан иде. Әле мәктәпне яңа платформага күчерергә җыеналар.

Мәктәптән башлана

16 августта башкалабызның Бәшир Рәмиев исемендәге IT паркында республика мәгариф хезмәткәрләренең август киңәшмәсе узачак. Мөгаллимнәр әлеге чарадан нинди яңалыклар көтә? Белем бирү системасында нәрсәләрне үзгәртергә кирәк?

Арман КОСТАНЯН, «Ел укытучысы – 2023» республика бәйгесе җиңүчесе, Югары Ослан районындагы Иннополис лицееның математика укытучысы:

– Яңа уку елында әллә нинди зур үзгәрешләр көтмим. Мәгариф системасы дөрес юлдан бара дип уйлыйм. Утыз ел элек мәгарифтә башкаларны куып тотарга тырышу дигән нәрсә булса, хәзер киләчәкне уйлап эш йөртәләр. Тик монда укытучыларның да заманнан калышмыйча алга баруы кирәк. Быел яңартылган стандартларга таянып эшли башлыйбыз. Һәр укучы белән аерым эшләүне, һөнәребезгә карата кызыксыну уятуны дәвам иттерәчәкбез. Укытучы өчен укучының мәктәптә алган белемне тормышта куллана белүе мөһим. Мәктәпләрдә остазлыкка, ягъни өлкән укытучыларның яшьләргә булышуына, уртача белем нәтиҗәләрен күтәрүгә омтылуга, тәрбиягә зур игътибар бирелә.

Мария НЕФЕДОВА, «Белем» Россия җәмгыятенең республикадагы филиалы башкарма директоры:

– «Белем» оешмасының төбәк җитәкчесе буларак, республикада, ниһаять, Россия җәмгыятенең мәгариф проектларының бөтен куәтенә тормышка ашырыла башлавын көтәм. Болар бигрәк тә укучылар, студентларга кагыла. Без төбәккә кызыклы федераль, шулай ук республика белгечләрен чакырырга җыенабыз. Бу чаралар яшьләрне тарту ноктасы булыр дип ышанам.

Алексей ЛОПАТИН, Казан илкүләм тикшеренүләр техник университеты (КАИ) галиме:

– Гадәттә август конференциясендә күбрәк мәктәп һәм урта һөнәри белемгә игътибар бирелә. Вузлар федераль карамакта бит. Әмма республикада университетлар да читтә калмый.

Гомуми белемгә килгәндә, республикада ел саен яңа заманча мәктәпләр ачыла. Әйтик, быел Казанда гына 4 яңа мәктәп эшли башлаячак. «Кайда укытырга?» дигән сораудан соң «Кем укытыр?» дигәне туа. Яшерен-батырын түгел, республикада укытучылар кытлыгы бар. Киңәшмәдә педагоглар белән тәэмин итү турында да сөйләшсеннәр иде. Мине бигрәк тә техник, инженерлык юнәлешләре борчый. Математика, физика, химия, информатика, технология укытучыларына ихтыяҗ бар. Информатикадан имтихан бирүчеләр күп, ә менә математика (профиль юнәлеше), физиканы сайлаучылар аз. Математикадан БДИ тапшыручыларның кимүе бер дә сөенечле хәл түгел. Математика – фәннәр патшасы. Әгәр укучы әлеге фәннән имтихан сайламаса, техник кына түгел, икътисад, менеджмент юнәлешләренә дә укырга керә алмаячак. Математика укытучыларын мәктәптән үк җитди әзерли башлау мөһим. Әти-әниләр белән еш аралашырга тырышам. Алардан, укытучылар үзләре дә хата җибәрә, дигәнне дә ишетергә туры килә. Шуңа күрә укытучыларның үз фәнен яхшы белүе кирәк. Быел республикада «Безнең яңа укытучы» грантының яңартылуы – күңелле хәбәр. Вузларда химия, физика һәм башка юнәлешләрдә укыган белгечләр, бәйгедә катнашып, мәктәпкә укытырга кайта алачак. Укытучы һөнәренә мәктәп эскәмиясеннән үк кызыксыну уяту кирәк. Яшь укытучы үзенең үсеш траекториясен дә күрә алсын иде. Укытырга гына түгел, директор булырга теләүче яшьләр дә бар бит.

Бердәм укыту программаларына күчүне хуплыйм. Укытучыга җиңелрәк булачак дип уйлыйм. Ни өчен дигәндә, укыту алымнары, дәреслекләр күп. Ә укытучыга барысын да аңларга кирәк. Тик имтихан биргәндә, укучыга зыян килерлек булмасын иде. Ун ел буе бер дәреслектән укып, 11 нче сыйныфка җиткәч, уку әсбабы үзгәрсә, бу бер дә дөрес булмас. Системаны җимерүгә генә китерәчәк.

Өйдә уку мөмкинлеге булырга тиеш дип саныйм. Әмма мәктәптән китүчеләр арта башласа, уйланырга бер сәбәп. Проблеманы ачыкларга кирәк булачак. Бу – балалар буллинг, ягъни кыерсыту аркасында өйдә белем алуга күчә дигән сүз түгел. Мәктәптә кайсыдыр белемне йә аз, йә күбрәк бирәләр. Әти-әни шуңа күрә укытуның башка формасын сайларга мәҗбүр. Тик өйдә аралашуга һәм тәрбиягә игътибар җитми дип уйлыйм. Әти-әниләр эштә бит.

Сәрия МИФТАХОВА

Сан

Татарстан мәктәпләрендә – **3194**, Россиянең башка төбәкләрендә **1340** татар теле укытучысы белем бирә.

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Маленков коймагы

Сталин вафатыннан соң, Никита Хрущев КПСС-ның Беренче секретаре булып алганчы, СССР белән ярты ел идарә иткән Георгий Маленковны бик үк белеп бетермибез кебек.

Әлеге җитәкчене искә төшерү шуннан: моннан нәкъ 70 ел элек, нәкъ шул кеше, СССР чорында беренче булып, социализмга «кеше чырае» кертергә, башкача әйткәндә, ил икътисадын гади эшче, крестьян ягына йөз белән борырга алына. Сталин заманы тәртипләрен, ул чорда яшәмәсәк тә, яхшы беләбез. Ул репрессияләр генә түгел. Ул – гади кешедә дәүләтнең кечкенә бер шөребен күрү, аның мәнфәгатьләре, ихтыяҗлары белән исәпләшмәү, тормыш-көнкүреш шартларының түбәнлеге. Авыл кешесенә ул чорда эшчегә караганда да авыррак була. Нәкъ менә Маленков 1953 елның августында узган СССР Югары Советы сессиясендә яңа икътисадый курс игълан итә. Ул курс буенча ил хуҗалыгында өстенлек җиңел һәм азык-төлек сәнәгатен үстерүгә, халык куллану товарлары күпләп булдыруга бирелә.

Шул елны ук оборона чыгымнары кыскартыла, авыл җирлегендә хезмәт куючыларга (ул елларда авылларда халык шәһәрдәгедән күбрәк яши) салымнар сизелерлек киметелә, сатып алу бәяләре арттырыла, җыелып килгән бурычлар (недоимкалар) гамәлдән чыгарыла. Җир кешесенә, ниһаять, бәхет елмая. Әлеге курс белән ил бары ике ел тирәсе генә яшәп калса да, крестьян җиңел сулап куя, чагыштырмача яхшы тормышны, аның тәмен, рәхәтен күпмедер татый. «Маленков килде – коймаклы итте» («Пришел Маленков – поели блинков») дигән сүз илленче еллар уртасында шактый популяр була…

Дәүләтләр төрле булган кебек, алар тоткан икътисадый сәясәт тә бер-берсеннән нык аерыла. Әле бүген дә халык, гади кеше мәнфәгатьләрен беренче урынга куйган, шуны кыйбла иткән илләр булган кебек, гражданнарны дәүләт, аның ихтыяҗлары өчен асраганнар, гавамны артык «азындырмаганнар», бил каешын кысыбрак бәйләткәннәр дә җитәрлек. Соңгы категориягә кергән илләрдә гражданнар яшәеш сыйфаты, аның югарылыгы белән гадәттә артык мактана алмый. Без биредә, әлбәттә инде, Африканың хәерче дәүләтләре, Үзәк Америка банан республикалары, Көньяк Азиядәге фәкыйрь илләр турында сүз алып бармыйбыз. Үсеш алган илләрне күздә тотабыз. Андыйларны геосәясәтне белмәгән, аның белән шөгыльләнмәгән күпчелеккә һәм дә ул юнәлешне үз иткән азчылык дәүләтләргә бүләргә була. Менә шул геосәясәт, тормыш-яшәеш дигәндә, күп нәрсәне билгели, күп нәрсәләргә киртә куя да инде. Геосәясәт ул – күрше-тирә илләргә, бөтенләй чит кыйтгаларга урнашкан дәүләтләргә йогынтылылык, аларны үз фарватерыңа куып кертеп, шунда тотарга тырышу һәм тоту. Андый мәрәкә галәмәт күп акча, көч таләп итә. Әле тагын шунысы да бар: ул очракта охшаш сәясәт алып барган башка шундый дәүләтләр белән дә аркан тартышасы, йогынты зоналары өчен көрәшәсе, ярышасы. Тик шунысы хак: аякны юрганга карап сузмыйча, геосәясәткә баштанаяк чумдыңмы, халыкны бай һәм хөр итәм димә инде.

«Халыклар атасы» чоры да олы геосәясәт еллары була. Сугыш беткәч, ил чабатадан чыгар-чыкмас көе, социализм көчләп тагылган Көнчыгыш Европа илләренә (дистәдән арткан ил) саллы ярдәм күрсәтеп тору, АКШ белән атом бомбалары, аларны кирәк җиргә илтеп ташларлык очкыч, ракеталар саны буенча ярыш. Болар ил икътисадын хәлсезләндереп кенә калмый, аны берьяклы да итә. Моны Сталин янәшәсендәгеләр дә яхшы күрә. Тик юлбашчыга аны син әйтеп, аңлатып кара! Әлбәттә, беркем дә базмый. Ә менә аның вафатыннан соң… Маленков Министрлар Советы Рәисе (хәзергечә әйткәндә, премьер-министр) постында ил руленә Хрущев килгәч тә ел ярым тирәсе утыра һәм август сессиясендә алынган курсны дәвам итә. Тик 1955 елда «коймаклы чор»га – «Маленков НЭПы»на барыбер чик куела.

Ни өчен Маленков башлаган эшнең гомере шулай кыска була соң? Сәбәпләр берничә. Август сессиясеннән соң әлеге җитәкченең халыкта популярлыгы артык югары күтәрелә. Янәшәдәгеләргә ул ошамый. Ил белән җитәкчелек иткән дәвердә партия Үзәк Комитеты секретаре вазыйфасыннан китү дә аңа файдага булмый. Беренче секретарь постын Никита Хрущев алгач, партия белән хөкүмәт арасында көндәшлек башлана. Бу вакытта Маленков мөшкел хәлдәге колхозлар җирен крестьяннарга өләшү, ягъни мәсәлән, фермерлар хәрәкәтен башлап җибәрү идеяләре белән янып йөри. Коммунистик караштагы торган элита моны, әлбәттә инде, кабул итми. Әлеге хәл дә Хрущевка өстәмә очколар китерә. Беренче секретарь хәрби чыгымнарны кыскартуны да империалистлар тегерменәнә су кою дип бәяли. Шушындый хәлләрдә партия хөкүмәтне җиңеп кенә калмый, үзенә буйсындыруга да ирешә. Үзәк Комитетның 1955 елның гыйнвар азагында узган пленумы Георгий Маленковны Хөкүмәт рәисе вазыйфасыннан азат итә. Хрущев илгә берүзе баш та, түш тә булып кала.

Тагын авылны кысрыклау, авыл кешесенең бакча мәйданнары, шәхси хуҗалыгы белән көрәш китә. МТСлар таратыла, аграр секторда интенсив чаралар урынына экстенсив (чәчүлек мәйданнарын арттыру – чирәм җирләрне сөрә башлау) алымнар өстенлек итә башлый. Нәтиҗә үзен озак көттерми: 1963 елда СССР, үз тарихында беренче тапкыр, ашлыкны капиталистик илләрдән сатып алырга мәҗбүр була. Ә 1964 елда ил элитасы, Беренче секретарьга каршы астыртын берләшеп, аны отставкага озата…

Шәхес культын фаш иткән кеше Никита Хрущев булса да, ул гамәл – сәяси фаш итү, шул ук репрессияләрне, аларның масштабын халыкка ачып салу. Ә Георгий Маленков дигәндә, ул юлбашчының икътисадый сәясәтенә рәхимсез ревизия ясый. Бу урында без сөйләгән кешенең Сталинсыз үткән беренче киңәшмәдә үк «шәхес культы» төшенчәсен куллануын да искәртү кирәктер. Ахыр килеп: «Икътисадны яхшы аңлаган затлар хакимияттә озаккарак калганда, без бүген, ихтимал, гел башка тормышта яшәр идек», – диясе генә кала.

Ватан хакына

И-И ГАЗИЗЛӘРЕМ!

Бертуган сеңлем Роза: «Без бер-беребезгә бик охшаган, абый. Кеше белән аралашмыйча тора алмыйбыз», – дип әйтергә ярата. Моңа кадәр Балык Бистәсендә яшәде ул. «Мине ким дигәндә ярты Рыбный белә!» – дип горурлана иде. Инде менә күптән түгел Казанга күчеп килде. Әле җүнләп урнашып та бетмәгән, әмма әллә никадәр кеше белән танышып-дуслашып өлгергән. Беркөнне: «Абый, сине ике әби белән таныштырасым килә, газетага язарлык кешеләр», – дип шалтыратты. Минем кебек, һәрнәрсәгә гаҗәпләнә, соклана белә сеңлем.

Ул әйткән ике әби, чыннан да, сокланырлык кешеләр иде. Сиксән яшьне күптән узган булсалар да, «лаеклы ял»да өйдә утырасылары килмәгән. Авыл кешесе гомер буе алны-ялны белми яши бит инде ул. Шуңа күрә кул кушырып өйдә утырса, бу бик сәер тоелыр иде. Рәйсә һәм Әлфия апалар Украинада махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә эчке кием, күлмәкләр тегә, оекбашлар бәйли башлаганнар. Андагы хәлләрне телевизордан карап баралар икән. Бик белгән кеше кебек тезеп китте болар: «Егетләрне җәлләп үләбез инде. Алар да – кемнәрнеңдер газиз балалары бит. Эчке киемнәрен юарга су да юк икән. Бер кияләр дә ташлыйлар ди. Ә алмашка кием дә юк икән. Әле дарулар да җитми дип ишеттек. Вакытында ашый алалармы икән инде, бичаралар…»

Ике әби дә – авыл кызлары. Рәйсә апа Зиннәтуллина – Әтнә районының Югары Сәрдә авылыннан. Әлфия апа Джураева – Кама Тамагы районының Кече Бортас авылыннан. Хатын-кыздан яшен сорамыйлар, ди үзе. Әмма мин сорамый түзә алмадым. Рәисә апага – 88, Әлфия апага 84 яшь икән. Кем әйтмешли, намазлык өстендә генә утырыр чаклары. Әмма, тыныч утырып буламыни, диләр. Фронтка ярдәм итә башлаулары да күңел тынгысызлыгыннан килә. Җитмәсә, Әлфия апаның кызы Зөһрә, Рәйсә апаның туганының кызы Ләлә волонтерлар да икән. Минем киләсен аларга да әйткән булганнар. Ә тегеләр безнең исемне язмасын дигәннәр. Хәрби сер булганга түгел. «Безнең шикеллеләр күп монда. Безне генә аерып язса, башкалар алдында уңайсыз», – диләр икән. Нәрсәсе уңайсыз инде аның, кызлар! Сезне телгә алуыбыз күккә күтәреп мактау өчен түгел, ә башкаларга гыйбрәт өчен бит. Әнә Рәйсә апа нәрсә ди. Шул тирәдә яшәүчеләргә, әйдә, безгә сез дә кушылыгыз, дип әйткәләп караган. Ә аңа: «Пусть государство заботится», – дигәннәр. Рәйсә апа үзе, безнең нәсел гомер буе ярдәмчел булды дип, горурланып йөри. Заманында ательеда эшләгән ул. Һәм 1961 елда сатып алынган тегү машинасы бүген дә текелди. «Инде 90 солдатка трусик тектем, энем, менә материал бетеп китте әле», – ди. Инде тик тормас өчен, солдатларга җибәрергә алма киптерә башлаган бу. Ә Әлфия апа, сугыш коралларын дошман күзеннән яшерер өчен, маскировка челтәре үрүдә катнаша икән. «Бу конвейер сыман инде. Мин тиешле озынлыкта, тиешле киңлектә тасмалар кисеп утырам», – ди. Чимал җитмәгәндә, тасма өчен кешедән иске оеклар җыя башлаган. Бу патриот әбиләрне инде күрше-тирә йортларда яшәүчеләр күрә, таный, исәнләшеп йөри. Сеңлем Роза: «Син килеп киткәч, әбиләрнең абруе тагын да күтәрелде», – ди. Белсеннәр алар турында! Рәйсә апа туганы Раузаның кызы Ләлә волонтер икәнен дә, солдатлар өчен кыш буе җылы оекбаш бәйләвен дә, Украинадагы вакыйгаларны телевизордан карый-карый, авыруларга сабышып бетүен дә белсеннәр.

Әлфия һәм Рәйсә апалар – сугыш җиле кагылган буын. Әлфия апа: «Әбинең өч улы сугыштан кайтмаган. Аларның кайда күмелгәннәре дә билгесез. Моңа ана йөрәге ничек түзгәндер…» – ди. Рәйсә апаның әтисе Бөек Ватан сугышы башланырга өч ай калганда үлеп киткән. Гаиләдә бүтән ир заты булмаган. Аның каравы әти-әнисенең туганнан туганнары, үзләре теләп, яу кырына чыгып киткәннәр. Боларын ни өчен язам? Ватанны саклау, ватанпәрвәрлек хисләре әллә геннар буенча да килә микән, ил кайгысын үз кайгысы дип кабул итү өчен, бәндә баласы үз гомерендә гел михнәт күреп яшәргә тиеш микәнни, дим.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ил кайгысын үз кайгысы дип кабул итүче буын кешеләре бу!

Минем ватанпәрвәр әбиләрем әле сөлгеләр дә, оекбашлар да, күлмәкләр дә җыя башлаганнар. Миңа: «Энем, син дә эшеңдәгеләргә әйт әле: артык киемнәре булса, ташламасыннар. Түлке, күлмәкләре синтетика булмасын, һава сулый торган булсын», – диделәр. Рәйсә апа фронтка бераз акча да күчергән. «Күп түгел инде ул, ну берәр нәрсәгә ярап куяр әле», – ди.

Безнең сөйләшкәнне сеңлем Роза бик игътибар белән тыңлап утырды. Аның улы Илнар да Ватан алдында үз бурычын үтәп, «кайнар нокта»ларда булып, өйгә исән-сау кайткан иде. Әмма тыныч тормышта фаҗигале төстә вафат булды. Сеңлемнең Ватан солдатлары язмышына битараф булмавы, бәлки, шуңа да бәйледер. Ул да Украинадагы егетләребезгә берәр төрле ярдәм итү турында уйлап йөри икән. Өйгә кайткач, Рәйсә, Әлфия апалар турында хатыныма да сөйләдем. Ул әбиләр чын геройлар икән бит, ди. Әбиләргә кушылып, без дә берәр төрле ярдәм итү турында сөйләштек. Саубуллашканда әбиләрем: «Энем, язганнарыңны кайда укырбыз соң?» – диделәр. «Ватаным Татарстан» газетасында чыгачак, дидем. Бик сөенештеләр газизләрем. Аларны кочаклап, чал чәчләреннән сыйпыйсы килеп китте. Редакциягә кайткач, аларны газетабызга яздырттым. Бу кечкенә генә яхшылыгымны зур бүләк итеп кабул иттеләр әбиләр. «Үзебезнең ишегалдында татарлар белән җыелышып укырбыз», – диделәр. Озын гомерле булыгыз инде, әбекәйләр!

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Сәламәтлек

КАРАМА ЯШЕНӘ...

Сәламәтлек – авырулар булмау гынамы? Озак яшәүнең сере нидә? Казанда узган «100% Татарстан. Сәламәтлек формуласы» онлайн форумында әнә шул сорауларга җавап эзләделәр.

Чараның модераторы, Россия спортчысы Ирина Слуцкая ярты ел нәтиҗәләре буенча Татарстанның Россия һәм Идел буе федераль округында демографик күрсәткечләр буенча алдынгы урынны саклавын билгеләп үтте. Аның сүзләренчә, бу Татарстанда балалар тудыру һәм тәрбияләү өчен шартлар булдырылуы турында сөйли. Моннан тыш, республикада озак яшәүчеләр саны арта.

– Хатын-кызлар бала таба һәм моннан курыкмыйлар. Өстәвенә шактый яшь чакта табалар, бу зур өстенлек булып тора. Республикада спорт объектлары һәм сәламәтлек саклау объектлары күп булганга, халык актив яшәү рәвеше алып бара, – диде Ирина Слуцкая. – «Спорт белән шөгыльләнү кыйммәт» дигәнне еш ишетәм. Бу – сәбәп эзләү генә. Теләгән кеше бара да шөгыльләнә. Лидерларның үз мисалында моны күрсәтүе мөһим.

Озак яшәү сере турында 3 августта 90 яшьлек юбилеен билгеләп үткән Россия Кораллы Көчләре ветераны Вәдүт Хәкимовтан сорадылар. Яшенә карамастан, Вәдүт Хәкимов иҗтимагый эшләр белән актив шөгыльләнә, яшьләр арасында патриотик тәрбия буенча эш алып бара. «Сезне нәрсә дәртләндерә?» дигән сорауга ул: «Яшьләр һәм 67 ел бергә яшәгән яраткан хатыным», – дип җавап бирде.

– Мәктәп эскәмиясеннән җәй көне – җиңел атлетика, кыш көне чаңгы белән шөгыльләндем. Бөтен тормыш спорттан тора, – дип сөйләде ветеран. – Тормыш иптәшем Гөлсинә белән инде 67 ел бергә яшибез. Бер-беребезне яратабыз. Ул күбесенчә үзе турында түгел, ә кешеләр турында кайгырта. Мин аны медицина институтына бирер идем. Мине дә 90 яшькә кадәр яшәтте. Бүген ул минем белән җитәкчелек итә. Иртән торып, башта физик зарядка, аннан сулыш гимнастикасы эшлибез. Менә шулай яшибез.

Өлкән буын белән эшләү турында Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сөйләде.

– Татарстанда яшәүче һәр дүртенче кеше – пенсионер. Бүген республикада 100 яшьтән өлкәнрәк 174 кеше яши. Дәүләт өчен бу кешеләрнең тормышы бай һәм кызыклы булуы мөһим, шуңа күрә һәр районда актив озын гомер буенча төрле программалар эшли. Спорт, мәдәни һәм ял чаралары өлкәннәр өчен мәдәният сарайлары, ветераннар советлары каршында үткәрелә. Бу өлкән яшьтәге кешеләргә актив булырга мөмкинлек бирә, – диде министр.

vk.com

Мисал өчен, ел саен Татарстан Рәисе ярдәме белән «Өченче яшь университеты» программасы уза. 21 мең пенсионер 16 юнәлеш буенча дәресләргә йөри. Дин тарихы, туган якны өйрәнү, бакчачылык, ландшафт дизайны буенча белем алырга мөмкин. Министр сүзләренә караганда, компьютер грамоталылыгы буенча дәресләр аеруча популяр. Пенсионерларга мошенникларның хәйләләренә эләкмәскә, смартфон кулланырга, банк картасы белән эш итәргә аңлаталар.

«Хәрәкәтсез яшәү рәвеше Альцгеймер авыруы куркынычын 3 тапкыр арттыра». Хәтер һәм баш мие үсеше буенча тренер Андрей Сафронов әнә шулай дип кисәтте. Андый яшәү рәвешен Көнбатыш белгечләре тәмәке тартуның яңа төре дип тә атыйлар икән.

– Бу бик җитди. Теләсә нинди авыру беренче симптомнар барлыкка килгәнче 20–30 ел алдан башлана. Залга йөрү мәҗбүри түгел, атнага өч тапкыр 30 минут тиз йөрергә тырышыгыз. Сез каядыр соңга калган кебек йөрергә тиеш. Бераз тирләсәгез һәм йөрәк тибешегез тизләнсә, бу сезнең миегез өчен яхшы. Сәламәт йокы да мөһим. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, бер сәгать йокы җитмәү баш миенең танып белү функциясен сизелерлек киметә, – дип сөйләде Андрей Сафонов.

Ләйсән САФИНА

БУЙДАК ЙӨРӘГЕ СЫНАТА

Соңгы елларда Татарстанда йөрәк-кан тамырлары авырулары аркасында теркәлгән үлем-китем очраклары кими бара. Шулай да тынычланырга иртәрәк. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш кардиологы Зөлфия Ким шулай дип кисәтә.

Үлем-китем очраклары кимесә дә, йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан интегүчеләр саны үзгәрешсез кала, ди белгеч. Моның төп сәбәбен хәзерге тормыш рәвешебездә күрә ул.

– Бүген бит хәрәкәт кимеде. Күпләр, зарары азрак дигән булып, электрон тәмәке тарту белән мавыга. Йокың туйганчы йоклау да сирәк күренешкә әверелеп бара. Көндәлек тормышта даимигә әйләнә барган стресслар да йөрәккә бәрә. Югыйсә беренче карашка гади тоелган киңәшләр күп кенә авыруларны кисәтеп кенә калмыйча, кеше гомерен саклап калырга да мөмкин. Бу очракта йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан үлем-китем ихтималын 40–50 процентка киметеп була, – ди Татарстанның баш кардиологы.

Йөрәк сагында торган белгечләр туклануга да игътибар итәргә чакыра. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш нутрициологы Оксана Фролова бу очракта клетчаткага бай ризыкларга (карабодай, фасоль, кишер, помидор, борчак, киви, алма һ.б.) өстенлек бирергә киңәш итә.

– Йөрәк, кан тамырларын ныгыту өчен организмга көненә ким дигәндә 35–40 грамм клетчатка керергә тиеш. Күз алдына китерү өчен: 1,5 килограмм кишердә нәкъ менә шуның кадәр клетчатка бар. Көндәлек рационда балык та булсын. Диңгез балыгы булса, бигрәк тә яхшы. Караҗимеш белән күрәгә дә йөрәкне ныгыта, – ди табиб.

Белгечләр көн дәвамында кулланылган тоз күләмен чикләргә куша. Ул 5 граммнан да артмаска тиеш. Ит ризыкларын да чама белән генә ашарга киңәш итә алар. Юкса халыкта ит ашамаган кешенең йөрәге зәгыйфьләнә, дигән фикер яши. Чынлыкта, белгечләр аны атнасына күп дигәндә ике тапкыр ашау да җитә дип ышандыра. Йөрәк өчен иткә караганда, балык файдалырак, ди алар.

Табиблар яшерми: хәзер организмга кирәкле барлык витамин, файдалы матдәләрне ризык аша гына туплап бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә сәламәт булу өчен безгә ел дәвамында витаминнар да эчәргә туры килә. Күпләр бу максатта БАДлар белән дә мавыга. Табиблар исә моны белгеч белән киңәшләшкәннән соң гына эшләргә ярый, дип кисәтә.

– Төрле витамин, БАДларны үз белдегең белән генә эчәргә ярамый. Әйтик, даими рәвештә кан сыеклата торган дару эчеп торган кеше үз белдеге белән генә БАД эчә икән, аның каны сыекланып, кан китә башларга яки киресенчә, куерып, тромб барлыкка килергә мөмкин, – ди Зөлфия Ким.

Йөрәк авыруларыннан интеккән кешегә җәй көне кояш чамадан тыш кыздырган сәгатьләрдә урамга чыкмыйча торырга да киңәш итә ул. Бу мәлдә бакчада казынып яту да кирәкмәс.

– Җәйге челләдә кондиционер белән дә артык мавыгырга ярамый. Көн дәвамында чиста су эчәргә дә онытмаска кирәк. Кан басымын да контрольдә тоту хәерле, – ди табиб.

Статистикага ышансаң, ирләр йөрәк авыруларына ешрак бирешә икән. Хатын-кызлар арасында бу чирләр, нигездә, менопауза чорына кергәч күзәтелә башлый. Шуңа күрә белгечләр йөрәк сагында тору бурычын да хатын-кызларга йөкли.

– Өйдәге һава торышы хатын-кыздан торган кебек, гаилә әгъзаларының саулыгы да еш кына хатын-кызга бәйле. Буйдаклар йөрәк-кан тамырлары авыруларына ныграк бирешә. Бу инде фәнни расланган. Шуңа күрә гүзәл затларыбыз үзенең һәм якыннарының йөрәген саклауга аеруча җаваплы карасын иде, – ди Зөлфия Ким.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Йөрәк саклanганны гына түгел, хәрәкәтләнгәнне дә ярата. Күптән түгел Британия галимнәре көн саен ярты сәгать җәяү йөрүнең гомерне 16 елга озайтуын ачыклаган.

Спорт медицинасы табибы Нияз Бикчурин сәламәтлекне ныгыту өчен күбрәк җәяү йөрергә киңәш итә. Анысының да рәте бар. Йөрәккә файдасы булсын өчен, эленке-салынкы атлап түгел, ә бераз кызурак – азрак тын кысыла башланганчы йөрергә кирәк икән.

– Сәламәтлек өчен җәяү йөрүдән дә яхшысы юк. Йөгерүгә караганда да файдалырак ул. Җәяү йөрү гәүдәне төз тотарга да ярдәм итә. Скандинавия йөрешенең дә йөрәккә файдасы әйтеп бетергесез зур, – ди табиб.

ИДЕЛ ЯРЫНДА – ТАТАР ЭЗЛӘРЕ

Автор фотосы

Без бел(мә)гән тарих

Быел, уйламаганда-көтмәгәндә, теплоходта сәяхәт итеп кайтырга булдык. Башта Санкт-Петербург дип сөйләнгән идек. Әмма юлламалар алырга соңга калган булып чыктык. Моңарчы Иделнең өске ягына чыкмаган булсак та, кабат, инде өченче тапкыр, Самара, Сарытау, Волгоград шәһәрләрен сайладык. Нишләптер, күңел гел шул якка тартыла. Ни өчен икәнлеген аңлыйм да кебек. Мин ерак бабаларымның эзләрен барлап йөрим, ахры. Экскурсияләрдә йөргәндә, татарлар турында сүз чыккан саен, горурлык хисләре пәйда була. Тарихны барлар өчен, әлбәттә инде, төбәк музейларын айкап чыгарга кирәк. Шуңа күрә дә шәһәрләрдә йөрергә билгеләнгән вакытның күп өлеше шунда үтте дип әйтергә була.

Самара

Өлкәдә яшәүче милләттәшләребезнең саны – 126152 кеше. Самараның үзендә – 39409. Шулай ук Тольятти, Сызрань, Похвистнево, Новокуйбышевск, Чапаевск, Жигулевск шәһәрләрендә һәм өлкәнең ун районында милләттәшләребез күпләп яши. Keләүле районында Назаровка дип аталган бердәнбер керәшен татарлары авылы урнашкан.

Татарлар Самара өлкәсендә сан буенча икенче урында тора. Гидлар, милләттәшләребез турында сөйләгәндә, «җирле халыклар» дип тә әйткәлиләр. Дөресе шул инде. Самараның тарихы татарга барып тоташа. Археологик казу эшләреннән күренгәнчә, бу җирләрдә Идел буе болгарлары беренче 1000 еллыкның ахырында яши башлый. Тарихта билгеле булган торак җирләрнең иң зуры – Муром шәһәрчеге. Аның һөнәрчеләре металл, зәркән, балчык, агач эшләре белән шөгыльләнә, тирә-якта дан тоткан үзәк була ул. XIII гасырның 30 нчы елларында, Батый хан яуларыннан соң, Урта Идел (шул исәптән Самара өлкәсенең бүгенге территориясе) Алтын Урданың иң төньякта урнашкан олысы булып кала. XVI гасыр урталарында исә бу биләмәләр Рус дәүләте составына керә. Екатерина Икенче идарә иткән елларда андагы буш җирләргә татарларны һәм Иделнең сул як ярындагы башка халыкларны күпләп күчереп утырта башлыйлар. Шуңа күрә татар авылларының күбесенә XVIII–XIX гасырларда нигез салынган дип исәпләнә.

Казаннан аермалы буларак, Самарада иске шәһәрне кадерләп саклыйлар. Сәяхәтчеләр өчен ул ачык һавадагы музей кебек. Безнең өчен иң мөһиме: монда татар рухы яши. Үзәк урам элек Мәчет урамы дип аталган (хәзер Самара урамы). Самарада сәүдә эшләрен Касыйм өязеннән килгән татарлар алып бара. Шул вакытта Мәчет һәм Татар (хәзер Галактионов) урамнары чатында Татар бистәсе барлыкка килә дә инде. Самара шәһәренең 1804 елгы геометрик планында татар сәүдәгәрләре өчен салынган йортлар, мәчет һәм татар мәктәбе күрсәтелгән, яңа мәчет һәм мөселман зираты өчен урыннар билгеләнгән.

XIX гасырда да Самарадагы татарларның тормышы югары кимәлдә була әле. Бу бигрәк тә 1844 елда Саратов (бүген Фрунзе) урамында мәчет төзүгә бәйле. Ә 1891 елда Сембер фабриканты Тимербулат Акчурин Казан (бүген Алексей Толстой) урамында йорт сатып ала һәм үз хисабына икенче мәчет төзи. Самарада өченче мәчет – Җәмигъ мәчете – 1912 елда Оренбург (бүген Чкалов) авышлыгында барлыкка килә. Аның төзелеше буенча попечительләр советы рәисе сәүдәгәр Мәхмүт Баишев була. XIX гасырның 80 нче елларында Казан урамында мәктәп белән мәдрәсә, китапханә ачыла, ике рус-татар мәктәбе эшли башлый. Революциягә кадәр «Икътисад» исемле журнал чыга. Инкыйлабтан соң башкалары да пәйда була.

Совет елларында исә күп мәчетләр ябыла, бары тик кайбер авылларда гына кала. 1967 елның декабрь аенда шәһәр башкарма комитеты мөселманнарның дини оешмасына намаз уку өчен йорт салырга рөхсәт бирә. 1985 елда ул мәчет итеп үзгәртелә һәм манара куела. Самара өлкәсендә бүген дә ата-бабаларның тарихын кадерләп яшиләр. Шәһәрдә «Туган тел» дип аталган мәдәният үзәге эшли. Ул өлкәнең башка шәһәрләрендәге оешмаларны да берләштерә. Бүген Самара өлкәсендә татарларның 20гә якын иҗтимагый оешмасы бар. «Яктылык» исемле татар мәктәбенең дә, өлкәнең – «Бердәмлек», Җәмигъ мәчетенең «Сәлам» исемле газеталарының да даны еракларга таралган. Ике телдә нәшер ителүче «Самара татарлары» журналы да татар тормышын яктырта.

Сарытау

Өлкәдә яшәүче милләттәшләребезнең саны – 52900 кеше. Сарытауның үзендә – 14800. Татарлар күпләп Сарытау, Энгельс шәһәрләрендә, Дергачев, Балаково, Пугачев районнарында яши.

Гидлар сөйләвенчә, Сарытау шәһәре 1584–1589 елларда татар авылы урынына төзелгән. Бу җирләрнең тарихы, чыннан да, борынгы төрки халык белән тыгыз бәйләнгән. Территория төрле чорларда Төрки һәм Хазар каһанлыклары, кыпчак кавеме, Алтын Урда һәм Ногай Урдасы составына кергән. 1680 нче елларда Сызрань-Пенза саклагыч чикләрен төзү өчен, төрле өязләрдән ясаклы татарлар күчерелә. Шулвакытта йомышлы татарлар һәм сәүдәгәрләрдән торган татар җәмгыяте төзелә. 1917 елга кадәр татарлар нигездә авылларда гына яши. Археологлар шундый йөзләгән авылның эзенә төшкәннәр. Кызганыч, аларның кайчандыр ничек аталганын да ачыклау мөмкин түгел. Әмма әйләнә-тирәдә Әхмәт, Караболак кебек төрки атамалар белән аталган торак пунктлар күп. Шунысы гына билгеле: тора-бара татарлар күпләп яшәгән Татар бистәсе шәһәр эчендә кала. Алар яшәгән урам бүгенгә кадәр Татар исеме белән йөртелә.

1835–1839 елларда Сарытауда таш мәчет төзелә. 1911 елда губернада 116 мәчет, 64 мәдрәсә һәм мәктәп эшләп килә. Китапханә белән уку залы эшли. «Мөхтәрият», «Ялкын», «Ярлы» газеталары нәшер ителә. Революциядән соң Сарытау татарлары зур ыргылыш ясап ала. 1926–1930 елларда губернада татар мәктәпләре, татар клубы, «Сандугач» җыр һәм бию ансамбле эшли. 1924 елда татар укытучылары әзерләү өчен педучилище ачыла. Татарча газета нәшер ителә.

Сарытау татарлары бүген дә бик актив яши. «Идел» мәдәният-мәгариф берләшмәсе, татар милли-мәдәни автономиясе, «Сарытау» яшьләр оешмасы милләттәшләребезгә «йоклап китәргә» ирек бирми. Сәяхәтчеләр өчен Сарытауда бик тә хикмәтле урын бар. Ул – «Сарытау өлкәсе халыкларының милли авылы» этнографик музее. Аңлашыла ки, анда безнең көнкүрешебезне күрсәткән Татар ишегалды үзенә чакырып тора.

Сарытауда туристларны беренче чиратта Соколов тавына алып меноләр. Монда ачык һавада Бөек Ватан сугышы музее урнашкан. Бу җирдә безнең өчен йөрәккә уелып калырлык тагын бер урын бар. Ул – тау итәгендә бабаларыбыз җирләнгән бик зур каберлек. Элек барганымда экскурсовод бу хакта үзе сөйләде. «Бу сары тауда, аның итәкләрендә татар авыллары булган. Каберлек бик борынгы», – дигән иде ул. Бу юлы искә алып торучы булмады. Шулай да бер турист очы-кырые күренмәгән каберлекләрне күреп алды да: «Бу нәрсә соң?» – дигән сорау бирде. Экскурсовод борылып карамыйча гына: «Ә-ә, татар зираты ул. Без бит – толерант халык. Шуңа күрә тимәскә, калдырырга булганнардыр», – дип битараф кына җавап бирде. Сүзне башка темага күчерде…

Язмамда шәһәрләрнең истәлекле урыннарына туктала тормадым. Барырга уйлаган кешегә ул хакта экскурсоводлар сөйләми калмас. Ә менә бу җирләрдә күпләп татарлар яшәгәнен, авыл-шәһәрләргә нигез салганлыгын бик әйтергә теләмиләр кебек. Әйтүне кирәк тапмыйлармы, әллә инде онытыламы? Монысы – икенче мәсьәлә. Ә менә безгә тагын да бердәмрәк булырга, телебезне, кем икәнлегебезне онытмас өчен тарихыбызны белергә кирәклегенә мин бу сәяхәттән тагын бер кат инанып кайттым.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Үзенчәлекле бәйрәмнәр

СӨЕНСЕН ӘЛЕ КҮҢЕЛ

Балык Бистәсе районында шәл бәйрәме уздырырга җыеналар. Яшел Үзән, Арчада исә самавырны искә алып, бергәләшеп чәй эчкәннәр. Эш дип яшәгән сала халкы да әкренләп ял итәргә өйрәнеп килә. Капка төбендә бәйрәм ясаучылар да юк түгел. Нинди генә чаралар уйлап тапмыйлар!

«Самавырдан чәй эчтек»

Яшел Үзән районының 150 йортлы Күгәй авылында табигатьтә гөрләтеп чәй эчкәннәр. Авылдашларны бәйрәмгә чакырырга җиз самавыр сәбәпче булган.

– Әлеге 40 литрлы самавырны заманында Горький заводында кулдан ясаганнар. Аны бары семинарларда гына тотканнар. Сәнгать җитәкчесе Рәмзия Заһидуллина: «Әйдә, шушы матур самавыр белән бәйрәм үткәрик әле», – диде. Һәр кеше өеннән дә самавыр алып килде. Беренче тапкыр уздыру гына әле. Егетләр мәш килеп су ташыды. Авылдашлар биеп-җырлап күңел ачты, тәмләп чәйләр эчте. Бу бәйрәмне киләсе елда зурлап күрсәтәсе килә. Бәлкем, самавыр бәйрәме безнең авылныкы булып китәр, – ди клуб мөдире Алмаз Шәйхенуров.

Бистә шәле

19 августта Балык Бистәсе районы шәлчеләрен җыймакчы. Анда беренче тапкыр «Бистә шәле» I республика хатын-кызлар халык һөнәрчелеге фестивале үтә. Район мәдәният бүлеге җитәкчесе Лилия Кәримуллина белдергәнчә, чарада ирләр дә катнаша ала. Районда андыйлар да юк түгел. Шәлне иң тиз һәм иҗади бәйләүчеләрне ачыклаячаклар.

– Бу – хатын-кыз кәсебенә багышланган фестиваль. 2019 елда Рәмзия Фәттахова челтәр үрү студиясен булдырган иде. Безнең районга гына хас үрнәгебез дә бар. Шәл бәйләүчелек Күгәрчен авылыннан җәелгән. Анда Зәйтүнә исемле укытучы кайтып, кызларны шушы шөгыльгә өйрәткән. Тора-бара әлеге шөгыль Ямаш, Балтач, Күки авылларына да тарала. Бүген рус, татар, керәшен ханымнары – барысы да бәйли. Районда шәлчеләрнең санын исәпләп бетерерлек түгел. Асыл затлар барысы да бәйли белә. Бистә шәлен республика халкына да күрсәтәсебез килде, – ди Лилия Кәримуллина.

Фестивальгә килүчеләр шәл бәйләүнең барлык нечкәлекләре белән таныша алачак. Осталар юу, тетү, эрләү, бәйләү буенча мастер-класс күрсәтәчәк. Татар халкының кул эшләнмәләренә багышланган фольклор күренешләре тәкъдим ителәчәк.

– Шәлне 7 яшьтән бәйлим. 41 ел буе остарып беттем инде. 15 ел клубта бәйләү түгәрәге алып бардым. Мине дә фестивальгә чакырдылар. Нишләп бармаска? Мондый чарада беренче тапкыр катнашуым. Хезмәтләремне дә күрсәтергә алып барам, – ди Татар Чаллысы авылы клубының сәнгать җитәкчесе Илшат Заһидуллин.

Кич утырганнар

Саба районының Иске Икшермә авылында биш ел элек капка төбендә кич утыруны гадәткә керткәннәр.

– Җәй көне авыл җирендә кеше клубка бик чыкмый бит. Эш күп. Бакчадан караңгы төшкәч кенә керә, кырда эшләүчеләр дә өенә соң кайта. Халык безгә килми дип аптырап тормадык, үзебез барырга булдык. Безнең авылда Кибәче очы дигән урам бар. Анда шундый җор телле Марзия, Сәрия, Мөнирә әбиләр яши. Алар җырын да, такмазасын да әзерләп куя. Гармун алып, башта шунда бардык. Киләсебезне белгәч, бик сөенделәр. Кеше күп җыелды. «Наза», «Биш парлы», «Гөлбану» һәм башка борынгы уеннарны уйнадык. Аннан инде икенче урамда күңел ачтык. Яшьләргә дә кызык. Хәзер ел саен июль аенда үткәрәбез, – ди мәдәният йорты мөдире Гүзәл Әхмәтҗанова.

«Сөлгеле капка»

Арча районының Ташкичү авылында исә «Сөлгеле капка» бәйрәме узган. Арча район мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе Ләйлә Хәкимова әйтүенчә, фестиваль районда икенче тапкыр үткәрелә. Идея исә – Ташкичү авылындагы данлыклы «Өммегөлсем» фольклор төркеменеке. Узган ел башлап җибәргән чарада катнашырга гариза бирүчеләр ике тапкыр арткан. Сарман, Балык Бистәсе, Ютазы һәм башка районнардан, Мари Элдан да иҗат коллективлары катнашкан. Алар халык җыры һәм биюләрен, инструменталь чыгышлар, этнографик күренеш номинацияләрендә чыгыш ясаган.

– Әби-бабайдан килгән гореф-гадәтләрне, башка коллектив тәҗрибәсен өйрәнү бит бу, – ди Ләйлә Хәкимова. – Күз алдына китерегез: авылдагы 600дән артык кеше милли киемнән урам буйлап, җырлап, мәйданга агыла. Авылны җанландырып җибәрү өчен дә кирәкле чара бу. Сөлгеле капка – үзенчәлекле бәйрәм. Монда кулдан чигелгән сөлге алып килергә кирәк. Һәр төбәк үз чигү үрнәкләрен күрсәтә. Без халыкның һөнәрчелегенә дә басым ясыйбыз. Татарның кунакчыллыгы капкадан ук башлана. Без дә кунакларны җырлап-биеп, сыйлар белән каршы алдык. Бәйрәм мари, керәшен, удмурт, рус һәм татарларны да берләштерә.

Шәл бәйләү хатын-кыз эше генә түгел икәнен раслыйлар Балык Бистәсендә!

Сәрия МИФТАХОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Яңа технологияләр мәктәбе» гомуми белем бирү оешмасы автоном коммерциясез оешмасы укытучысы **Рябкова** Ирина Алекандровнага **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Төзелеш өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Казан (Идел буе) федераль университеты югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Чаллы институты (филиалы) төзелеш технологияләре һәм күчемсез милекне идарә итү кафедрасы доценты **Әхмәтов** Фрил Мирзанур улына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Суд департаментының Татарстан Республикасындагы идарәсе эш башкару һәм контроль бүлеге башлыгы **Волков** Айдар Искәндәр улы, халык сәламәтлеген саклау эшендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Кукмара үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табибы – стоматолог-терапевты **Габдрахманов** Равил Габделбәр улы, транспорт белән тәэмин итү өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең эксплуатация бүлеге автомобиль йөртүчесе **Гобәев** Рәис Мәгъфур улы, Татарстан Республикасының мәдәни һәм тарихи мирас объектларын саклауга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе **Гущин** Иван Николаевич, финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе баш бухгалтеры урынбасары **Зайцева** Светлана Евгеньевна, республиканың ветеринария өлкәсендәге иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Зәй районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы – баш ветеринария табибы **Исламов** Фоат Габбас улы, һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнары хезмәттәшлеген координацияләү идарәсе башлыгы урынбасары **Кучекаева** Динә Сәгыйть кызы, республиканың азык-төлек сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татспиртпром» акционер җәмгыятенең «Усад спирт заводы» һәм «Усад ликер-аракы заводы» филиаллары директоры **Мәдьяров** Айдар Рафикъ улы, республикада мәҗбүри медицина иминиятләштерүе өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды» дәүләт учреждениесе директоры **Мифтахова** Алсу Мансур кызы, республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды башкарма директоры урынбасары **Никифоров** Владимир Геннадьевич, һөнәр берлекләре хәрәкәтен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең башлангыч һөнәр берлеге оешмасы рәисе **Никулина** Вера Александровна, республикада нотариат институтын үстерү эшенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Актаныш нотариаль округы нотариусы **Янгирова** Ләйсән Сөнгать кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе директоры урынбасары **Бәдретдинов** Динар Альберт улына, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең капиталь төзелеш объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә күзәтчелек буенча Көнбатыш территориаль органы җитәкчесе **Гайнетдинов** Илсур Юныс улына, «ТАТЭЛЕКТРОМОНТАЖ» акционер җәмгыятенең смета-шартнамә эшләре буенча план-җитештерү бүлеге башлыгы урынбасары **Евдокимова** Любовь Ивановнага, «Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 6 номерлы төзекләндерү-механика цехы башлыгы **Лысенко** Валерий Михайловичка, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе» муниципаль казна учреждениесе баш инженеры **Сәләхов** Марсель Вильянис улына, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Казан шәһәре буенча капиталь төзелеш объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә күзәтчелек итү территориаль органының 5 номерлы бүлеге консультанты **Третьяков** Александр Валентиновичка, «ТЕХНИК ЗАКАЗЧЫ-ТӨБӘК» акционер җәмгыятенең Идел буе дивизионы төбәк девелопменты буенча дирекциясе директоры урынбасары **Ураков** Сергей Валерьевичка, «Алексеевскдорстрой» ачык акционер җәмгыятенең участок башлыгы **Гыйззәтуллин** Рашат Талип улына, «Транспорт корылмаларын проектлау институты» акционер җәмгыяте генераль директоры **Григорьев** Андрей Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Көнбатыш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Әлмәт шәһәре) **Азизов** Ринат Гаяр улына, «Тәтеш җылылык челтәре предприятиесе» акционер җәмгыяте баш инженеры **Әхмәдгалиев** Илдар Мәхмүт улына, «Чистай җылылык челтәре предприятиесе» ачык акционер җәмгыятенең контроль-үлчәү приборлары һәм автоматлар участогы мастеры **Донцов** Евгений Алексеевичка, Казан шәһәренең «Шәһәрне төзекләндерү» муниципаль унитар предприятиесе катнаш комбинацияле юл машинасы машинисты **Калинин** Николай Андреевичка, Казан шәһәренең «Горводзеленхоз» су һәм агачлар-үсемлекләр утырту хуҗалыгы буенча шәһәр производство тресты» муниципаль унитар предприятиесе агач-үсемлекләр утырту эшчесе **Тазиева** Асия Кәрим кызына, Казан шәһәренең «Горводзеленхоз» су һәм агачлар-үсемлекләр утырту хуҗалыгы буенча шәһәр производство тресты» муниципаль унитар предприятиесе агач-үсемлекләр утырту эшчесе **Фәхертдинова** Руфия Гаптрәшит кызына, «Нурлат җылылык челтәрләре» акционер җәмгыяте идарәчесе **Шәрәпов** Рамил Шакир улына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Л.Я. Карпов исемендәге химия заводы» акционер җәмгыятенең 110 номерлы цехы гипосульфит тозлар җитештерү участогының абсорбция аппаратчысы **Татаренко** Владимир Анатольевичка **«Татарстан Республикасының атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Л.Я. Карпов исемендәге химия заводы» акционер җәмгыятенең чиктәш челтәр оешмалары участогы электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтеры **Вәлиев** Мосавир Миңнехан улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе нефть һәм газ чыгару департаментының җитештерү процессларына хезмәт күрсәтү идарәсе энергетика җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү бүлеге башлыгы урынбасары – җир өсте приводлары электр җиһазларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерү төркеме җитәкчесе **Савельев** Олег Геннадиевичка, «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыятенең «Чистай электр челтәрләре» филиалы Аксубай электр челтәрләре районы башлыгы **Телешев** Николай Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган энергетигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Яңа сезон

«Камал»данниләр көтәргә?

Галиәсгар Камал театры 118 нче сезонын быел тагын да иртәрәк – 18 августта ук ачып җибәрәчәк. Яңа сезоннан ниләр көтәргә? Нинди премьералар булачак? Бу хакта «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында сөйләделәр.

– Казан туристларга бай шәһәргә әйләнде. Театр каршындагы мәйдан халык белән тулы. Мондый вакытта без ишекләрне ябып утырсак, дөрес булмас иде. Шуңа күрә иртәрәк ачылабыз. Гадәти түгел, ләкин бу традициягә әйләнер дип уйлыйм, – диде Камал театры директоры Илфир Якупов.

Театрның яңа сезонга бәйле яңалыклары шактый. Быел беренче премьера да августта ук булачак.

– Август аенда премьералар чыгарганыбыз юк иде. Илгиз Зәйниев пьесасы буенча «Ситса туй» комедиясе 25 августта күрсәтеләчәк, – диде театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев.

Сезонның беренче премьерасы турында тәфсилләбрәк аның режиссеры Айдар Җаббаров сөйләде.

– Мюзикл форматында спектакль кую күптәнге хыялым иде. Илгиз Зәйниев пьесасына нигезләнеп, музыкаль спектакль әзерлибез. «Ситса туй» – бик җиңел, юморы көчле пьеса. Спектакльдә 2000 нче елларда халык арасында популяр булган бик күп җырлар яңгыраячак. Бу – Винера Ганиева, Салават Фәтхетдинов, Габделфәт Сафин, Наил Табанаков, Чәчкәнең җырлары. Җиңел, шул ук вакытта эчтәлекле спектакль булырга тиеш, – диде Айдар Җаббаров.

Яшь режиссер театр репертуарында бик уңышлы барган «Хуш, авылым» спектакленең өченче өлешен дә чыгарырга җыена икән.

– Ул тарихи материалларга, документларга нигезләнгән булачак. Форматы шундый ук кала. Тик бу юлы интервьюлар алып булмас, чөнки еллар буенча арткарак китәбез. Мине XVI гасыр кызыксындыра, – диде ул.

7 ноябрьдә театр Ркаил Зәйдулланың «Хан һәм шагыйрь» әсәре буенча «Игезәк» спектаклен тәкъдим итәчәк.

– Традиция буенча, 7 ноябрьдә – Марсель Сәлимҗановның туган көнендә – яңа спектакль күрсәтәбез. Ркаил Зәйдулланың «Хан һәм шагыйрь» әсәрен, исемен үзгәртеп, ниһаять, сәхнәгә чыгарабыз. Ул инде аны күптән язган. Моннан 7 еллап элек театрга алып килгән иде. Минемчә, бу – бик җитди һәм катлаулы әсәр. Ул тарихка нигезләнгән. Ләкин шулай да хәзерге көнгә бик туры килә, актуаль, – дип сөйләде Фәрит Бикчәнтәев. – Туфан Миңнуллинның «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә» һәм «Хушыгыз» трилогиясен сәхнәләштерү турында да күптән хыялланып йөрим. «Хушыгыз»ны куйган идем инде. Калган ике әсәренә дә мөрәҗәгать итәсем килде.

118 нче сезонның тагын бер премьерасын Колумбиядән чакырылган режиссер Алехандро Гонсалес куячак. Спектакль быел театрның репертуарыннан төшеп калган «Дон Жуан» урынын алачак.

– Академия театры буларак, без дөньякүләм драматургиягә дә мөрәҗәгать итәргә тиешбез, дип уйлыйм. Алехандро Гонсалес Шекспирның «Укрощение строптивой» әсәрен сәхнәләштерергә теләген белдерде. Ул бездә бер куелган иде. Зөлфәт тәрҗемәсендә «Тискәрегә авызлык» исеме белән барды, – дип сөйләде Фәрит Бикчәнтәев.

Камал театры Әлфия Авзалованың юбилей елында легендар җырчы турында да спектакль чыгарырга ниятли.

– Әле әсәр языльп бетмәде. Өлгерергә тырышырбыз, – диде баш режиссер.

Илфир Якупов театрның гастрольләре, фестивальләре турында да сөйләде.

– Сентябрьдә Саранск шәһәрендә Россиянең V милли театрлар фестивалендә катнашачакбыз. 11 сентябрьдә безнең театр фестивальдә «Исәнме, әни» спектаклен тәкъдим итә. Шулай ук сентябрьдә Ижевск һәм Пермь шәһәрләренә гастрольгә барачакбыз. Ә ул вакытта безнең бинада 22–24 сентябрьдә «Артмиграция» фестивале булачак, – диде Илфир Якупов.

Шулай ук 25, 26 сентябрьдә Камал театрында Максим Горький исемендәге Самара драма театры гастроле көтелә. 118 нче сезонда Татарстанның халык артистлары Зөлфирә Зарипова, Гөлсем Исәнгулова һәм Татарстанның атказанган артисты Рамил Вәҗиевнең юбилейлары үтәчәк.

Ләйсән САФИНА

kamalteatr.ru

«Ситса туй» җиңел, шул ук вакытта эчтәлекле спектакль булырга тиеш», – диде режиссеры.

ХЫЯЛЛАР ҺӘМ ХАТАЛАР

«Татар-информ» / Рамил Гали

Мин кулыма китап алам

«Фәхрине үтереп ташладылар». Юк, классигыбыз Галимҗан Ибраһимовның күренекле әсәре турында язарга җыенмыйбыз без. Әлеге язма – Равил Сабырның нәкъ менә шулай дип аталучы романын тәкъдим итү чарасыннан репортаж һәм күпмедер дәрәҗәдә авторның үзе белән фикер алышу. Бу әсәр укучыларда нинди фикерләр уятырга өлгергән? Ул кем турында һәм кемгә атап язылган?

Әллә повесть, әллә роман…

Журналист, язучы Равил Сабырның «Фәхрине үтереп ташладылар» әсәре 2021 елда Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе химаясендә үткәрелгән ябык әдәби конкурсның «Роман» номинациясендә III урынны яулаган иде. Конкурстан соң ул «Казан утлары» журналында дөнья күрде һәм менә күптән түгел Татарстан китап нәшриятында 1500 данә тираж белән басылып та чыкты.

Безнең кулларга әллә ни калын булмаган китап рәвешендә килеп эләккәнче, шактый озын юл узган әсәр икән ул. Пьеса итеп языла башлап, повесть булырга тиешле романның идеясе моннан 15 еллап элек бөреләнә башлаган.

– Чаллы театрында эшләгән чакта баш режиссер Фаил Ибраһимовның бүлмәсенә еш керә идек. Шунда режиссер Булат Бәдриев өстәленә озын бармаклары белән суга-суга: «Менә бер бүлмә, менә аның дүрт почмагы. Шул дүрт почмакка дүрт геройны утыртып куй да, мәш килсеннәр шунда. Шундый пьеса кирәк!» – дип аңлаткан иде берсендә. Бу идея кызык булып тоелды, һәм мин аны чынга ашыра башладым. Ниндидер урынга килеп җитеп, әсәрне алга таба ничек үстерергә кирәклеген аңлый алмагач ташладым, – дип искә ала автор. – Ялгышмасам, 2011 елда Камал театры чираттагы лаборатория уздырды. Анда режиссер белән драматурглар берләшеп, төркем-төркем эшләде. Безне Уфадан Айрат Әбүшаһманов белән «парлаштырдылар». Мин Айратка теге пьесаны укып күрсәттем. Озак кына фикер алыштык. Әмма шуларны утырып язарга вакыт та, мөмкинлек тә булмады. Ябык әдәби конкурс игълан ителгәч, иптәшләр, хәтта җитәкчеләр дә, катнашырга кирәк, дип кыстадылар. Һәм мин янә шул әсәргә кайттым.

Үтереп ташладылар

Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты Дания Заһидуллина Равил Сабырның бу әсәрен «постмодернистик роман» дип билгеләде. Ә мондый төр әдәби әсәрләргә «катлы-катлы» мәгънәләр, аллюзияләр, цитаталар, сылтамалар хас була. Бик гади итеп әйткәндә, әзерлеге, тәҗрибәсе булмаган укучы өчен түгел алар. «Фәхрине үтереп ташладылар» романындагы постмодернистик алымнарга озаклап тукталып тормыйбыз. Хәер, аның берсе романның атамасында ук бар (Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар» әсәре шул сүзләрдән башлана). Сүз уңаеннан, шактый бәхәсле атама булды бит әле ул. Авторның бу җәһәттән фикерләрен тыңладык.

– Бәлки, мин укучының ачуын чыгарырга теләгәнмендер?! Бүген – сайлау мөмкинлеге ташып торган заманда укучының игътибарын җәлеп итү өчен ниндидер стандарт булмаган алым кирәк бит. Бәлки, бу очракта ул бәхәследер, әмма монда криминал юк, – диде ул. – Мондый алым дөнья әдәбиятында еш кулланыла. Поэма-шигырь юллары, халык мәкальләре төрле әсәрләргә, бигрәк тә кинофильмнарга кушыла.

Хаталар

Ниһаять, Равил Сабырдан әсәрнең эчтәлеге турында да берничә сүз.

– Эчтәлекне ике-өч сүз белән аңлату авыр. Безнең буынның үсмер һәм яшь чакта хыяллары нинди иде? Без нинди максатларга омтылдык? Һәм нәтиҗәдә нәрсә килеп чыкты? Ул чактагы һәм хәзерге күзаллау ни өчен аерыла? Шуның сәбәбен аңларга һәм аңлатырга тырыштым. Бу әсәрне 1990 нчы елларда Ирек мәйданында «Азатлык!» дип кычкырмаган, суверенитет өчен көрәшмәгән яшьләр аңлап та бетермәс. Мондагы аллюзияләр, цитаталарны, сылтамаларны аңлау өчен шактый тәҗрибә кирәк. Әмма әзерлеге булмаган укучы өчен сюжеты кызыклы булыр дип уйлыйм, – дип сөйләде ул безгә.

Сүз уңаеннан, хәзерге вакытта әлеге романны Әлмәт театры сәхнәсендә кую турында сөйләшүләр бара. Равил Сабыр сүзләренчә, пьеса инде языла башлаган. Аны режиссер Айрат Әбүшаһманов куячак.

> Айрат бу әсәрне «буын җаваплылыгы» турындагы роман дип атады. Безнең алда нинди мөмкинлекләр бар иде? Без аларны кулландыкмы, юкмы? Һәм ни өчен кулланмадык? Мондый анализ кирәк иде. Бәлки, бу – бик наив фикердер, әмма һәр буын үзе үткән юл турында ни дә булса әйтсә, аннан соң килә торган буынның хаталары азрак булыр иде. Билгеле, алар бөтенләй башка шартларда яшәргә мөмкин. Әмма аларга безнең тәҗрибә ярдәм итә ала.

Адәм баласы хатадан хали түгел, әмма ул хаталарны тану һәм анализлау өчен дә шактый көч кирәк бит. Бу яктан караганда, әсәрне язу ни дәрәҗәдә авыр булды икән?

– Бу бит ике-өч айда гына язылган әсәр түгел. Мин аның нинди биеклектә булырга тиешлеген яза башлаганда ук аңладым, әмма, күрәсең, ул чакта тормыш тәҗрибәм җитмәгән. 15 ел тәҗрибә җыю өчен аз вакыт түгел. Аннан соң, языла башлаганнан бирле әлеге әсәр тынгылык бирмәде, башка кереп утырды да һәрдаим анализларга этәреп торды. Күрәсең, ул шулай җитлеккән, «пешкән», – дип җавап бирде Равил Сабыр.

Сер итеп кенә тагын бер хикәя язуын да сөйләде ул. Озак кына әдәбияттан югалып торган драматург һәм язучының кире кайтуы булырмы бу? Монысын вакыт күрсәтер.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«Шулай итеп, җәмәгать, суд утырышында гаепләнүчеләр Илгизәр Сүлтиев, Хамис Шарафуллин һәм Галимҗан Гыйлемҗановларның эшләре тикшерелде, – диде Зөлмәт. – Моннан егерме ел элек болар өчесе дә: «Булган бөтен көчемне, мөмкинлекләремне татар милләтен дөньяда таныту эшенә сарыф итәрмен!» – дип ант эчкән. Тик егерме ел узуга карамастан, берсе дә бу антны үтәр өчен бармакка бармак та сукмаган. Судья Кадыйр Ширияздaнов карары нигезендә, өчесе дә кан тамызып эчкән антларын бозуда гаепле дип танылдылар».

Романнан өзек

ИЛГИЗ ШӘЙХРАЗИЕВ:

«ҮЗЕҢ ТЕЛӘГӘНЧӘ ЯШӘҮ ҖИҢЕЛ ТҮГЕЛ»

Гамьле әңгәмә

Башкаларга охшамаган ул. Һәм охшарга да тырышмый. Үзенең юлы белән матур гына, иплəп кенә бара. Сүзем – җырчы, автор-башкаручы, бетмәс-төкәнмәс энергияле Илгиз ШӘЙХРАЗИЕВ турында. Аның белән үзенчәлекле иҗат юнәлеше, тәнкыйть һәм ничек төрле була белү турында сөйләштек.

:: Иҗатыгызның юнәлеше бик үзенчәлекле. Бөтен кеше аңлап та бетерми…

– Бервакыт мин үземә теләсә нәрсә, кешеләр миннән таләп иткәнне җырламаска сүз бирдем. Хәзер эстрадада нәрсә популяр? Гади җыр, гади сүзләр белән. Чәчәкләр, гөлләр турында. Һәм алар бик күп. Үземнең җырларымны яза башлагач, минем башкарак юл белән барасым килде. Кешегә ошарга тырышу – бик җиңел юл бит ул. Ошарга тырышсаң, син ошаячаксың да. Чөнки син дөрес сүз сөйлисең, дөрес киенәсең, дөрес утырасың. Бу – кешеләр теләгән әйбер генә. Ә үзең теләгәнчә яшәү җиңел түгел. Мин шулай әкрен генә барам, минем – үз юлым. Беркемне дә гаепләмим, бөтенесе үз вакытында киләдер, дип ышанам. Тамашачыны белмим, үземне үзем дә бик аңлап бетермәдем әле. Кайчакта башка әллә нәрсәләр килә. Шундый бер фикер бар: үзеңнең иҗатыңны аңлату – иҗат кешесе өчен түбәнсенү.

> Үземнең иҗатымны аңласам, мин аның белән шөгыльләнмәс тә идем. Ә болай миңа кызык. Тамашачыга да шулай дип уйлыйм. Аңлашылган әйбер кызык түгел ул. Аңлашылып бетмәгәне кызык.

:: Тәнкыйть димәктән, аңа карата мөнәсәбәтегез ничек? Әйтик, халык җырларын бозып җырлыйсыз, диюләре турында.

– Тәнкыйтькә бик яхшы карыйм. Ул булырга тиеш. Гомумән, безнең илдә кем нәрсә тели, шуны сөйли алырга тиеш. Әмма миңа ошый яки ошамый торган тәнкыйть бар. Чын музыкант өчен бу – икеле-микеле нәрсә. Уйланыр өчен профессиональ тәнкыйть булырга тиеш. Борының кәкре, колагың зур диюләре тәнкыйть түгел, ул – факт. Халык җырларын бозу дигәндә, халык җырлары алар инде бар. Татар халкы ул җырларны алтын фондка кертте. Бик матур һәм оригиналь башкаруда. Хәзер инде аларны төрле жанрларда башкару мәдәниятебезне баета гына. Халык җырлары – халыкныкы. Мин дә – татар егете буларак, халыкның бер өлеше. Кемдер миңа татар халык җырын җырлама дип әйтә алмый, чөнки мин – татар. Мәсәлән, Илһам Шакиров халык җырын каяндыр бер авылдан ишетеп алып кайткан һәм үзенчә башкарган. Хәмдүнә Тимергалиеваның «Җомга көе»н тыңлап карасагыз, ул аның бер куплетын да бертөрле итеп җырламый. Чөнки музыкант кеше музыкага бүтәнчә карый. Алтмыш тапкыр бер куплетны бертөрле җырлау туйдыра. Җырчыны гына түгел, тыңлаучыларны да. Җырчының бурычы – тамашачыга җырны үзенчәлекле итеп тәкъдим итү.

:: Илгиз, сез ике тормыш белән яшисез кебек. Ничек сез шундый төрле була беләсез?

– Миңа ул бик җиңел бирелә. Үземнең бер образымнан да арымыйм. Мин бүген болай, иртәгә тегеләй. Зур-зур кунаклар булган дәүләт чарасында теләсә нәрсә эшләп булмый, билгеле. Һәрбер чараның үз дресс-коды, законнары бар. Туйга киләм икән, анда үземнең фәлсәфи җырларымны җырламыйм. Үземнең концертым булса, әлбәттә, аның «Әйдәгез, уйланып алыйк әле: ник тудык без бу дөньяга?» дигән бер өлеше була инде (*көлә*). Мин бөтен музыканы тыңларга, төрле-төрле жанрларны яратам. Ул жанрларда эшли торган музыкантларга кайчандыр гашыйк булганмын. Үземдә кайчакта шулардан отып алган алымнарны кабызам.

:: Аның кадәр энергияне кайдан аласыз?

– Мин мондый кеше түгел идем. Тыныч, тыйнак, акыллы идем (*көлә*). Миңа хәзер – 35 яшь. Яшь барган саен, кем нәрсә әйтә, нәрсә уйлый – мөһим түгел икәнен аңлыйсың. Иң мөһиме – мин. Үземнең кәефемне күтәрмәсәм, беркем дә күтәрми. Кешедән таләп итеп торсаң, димәк, син аларга бәйле. Нишләп мин үз бәхетемне, мәхәббәтемне, күңел халәтемне аларның кулларына тапшырырга тиеш? Минемчә, бу дөрес түгел.

:: Тел мәсьәләсенә дә тукталыйк. Ничек уйлыйсыз, татарча альтернатив музыка аша яшьләрдә телгә мәхәббәт уятып буламы?

– Мин бу проблема турында 2005 елда Казанга килгәч кенә белдем. Казан яшьләренең татарча белмәгәненә шаккаттым. «Аңлыйм, әмма сөйләшмим», – диләр иде. Соңгы елларда болай дип әйтми башладылар. Казанда үскән татар егетләре, кызлары күбесенчә татарча сөйләшәләр. Әлбәттә, музыка аша яшьләрдә телгә мәхәббәт уятып була. Минемчә, бу – бик яхшы ысул. «Альтернатив музыка» дигән төшенчә бер ун ел элек актуаль иде. Хәзер бу – безнең көнкүрешкә кергән җырлар. Яшьләр чит ил җырларын, рус телендәге җырларны тыңлый. Алар бүтән ритмнарда, сыйфатлы һәм дәртле. Яшь кешегә, әйтик, 15–16 яшьлек егеткә безнең радиостанциядә яңгыраган җырларны тыңлатсаң, ул аның белән кызыксынмаячак. Безнең яшь музыкантлар заманча жанрларда сыйфатлы җырлар язалар. Аларның татар телендә булуы әһәмиятле. Һәрбер заманның үз стиле, үз җырчылары була. Әйтик, Советлар Союзында яшәгән кешеләрнең җырлары, кинолары, хәтта сөйләшүләре дә бүтән булган. Ул вакыттагы җырларны бүген кертү яисә яшьләргә көчләп тагу дөрес түгел. Чөнки без хәзер яшибез, ул заманда түгел. Ә шул замандагы җырларны бүгенге көнгә яраклаштырып җырлау ул – тагын бер матур күренеш.

:: Мөмкинлек бирелсә, татар музыкасы дөньясында нәрсәне үзгәртер идең?

– Тамашачының жанрларга хәерхаһлырак булуын теләр идем. Тамашачының гына түгел, музыкантларның да. Эстрадага жанрлар төрлелеген кертер идем. Берсендә дустым Илмир Ямалов белән бер мәҗлестән кайтканда, татар телле радиоларны тыңлап барабыз. Беренче җыр: дуслар-туганнар белән җыелу, икенчесе – туй көне, өченчесе – 50 яшьлек юбилей турында. Мин үземне банкетта утырган кебек хис иттем. Эстрада әнә шул якка авышты. Чөнки банкетлар артистларны туйдыра. «Син сазыңны уйнадың», «Әдрән диңгез», «Зәңгәр томан» кебек саллы җырлар иҗат ителми диярлек. Серлелек, төрлелек җитми бүген.

:: 2013 елда бер әңгәмәдә сез: «Йолдыз булганчы эшләргә әзер», – дигәнсез. Хәзер үзегезне йолдыз итеп хис итәсезме?

– Үземне йолдыз дип әйтә алмыйм, әйтәсем дә килми. Мин – реалист. Чын йолдызлар – Зәйнәб Фәрхетдинова, Винера Ганиева, Салават абый белән аралашам. Хәтта алар да үзләрен «йолдыз» димиләр. Алар эшлиләр, җырлыйлар, сөйләшәләр. Гади кешеләр. Сәхнә артында эре кешеләрне, үзләрен «йолдыз» дип тотып йөрүчеләрне бик сирәк күрәм. Йолдыз ул, минемчә, бик өстә. Әлфия Авзалова, Илһам Шакиров кебек. Бер җырчы да үзен-үзе йолдыз итә алмый. Җырчыны халык йолдыз итә.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

ӘҢГӘМӘ ТУЛЫСЫНЧА VATANTAT.RU САЙТЫНДА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Илдар Мөхәммәтҗанов

Тәлгать ҖАМАЛЕТДИНОВ

КЫРЛАРДА – БОДАЙ, АРЫШ...

Авылга кайтып барыш.
Офыкка тоташкан
кырда –
Сап-сары бодай, арыш.

Тугай җыры ишетелә,
Кояшы шундый җылы.
Ходай биргән безгә быел
Икмәкле, матур елны.

Куанып туялмый күңел,
Никадәр байлык күреп.
Игенче үстергән аны,
Җирнең куенына төреп.

Күргәзмә залына түгел,
Кырларга сез килегез.

Менә кайда ул
Матурлык,
Менә кайда ул
Бәрәкәт,
Ил байлыгы диегез!

Горурлыгы туган җирнең,
Бар өмете, ышанычы,
Бүгенгесе, Киләчәге
Арыш-бодай кырында.
Игенче йөрәгеннән чыккан
Дәртле хезмәт җырында,
Ул җыр икмәк турында!

Авылга кайтып барыш.
Дулкыннар сыман йөгерә
Кырларда бодай-арыш.

ИКЕ ЯКТА – ИКЕ БҮРЕ

Әтием Әнәс Хәйруллин җеннәр, пәриләр бар дигән сүзләргә гомере буе ышанмады. «Серле, куркыныч әйберләрне, курыкмыйча, барып тикшереп карарга кирәк!» – дип әйтә иде.

Ул утыз ел буе Балтач районында киномеханик булып эшләде. Ә соңгы елларында Чапшар, Кили, Пүскән, Нормабаш, Курмала, Кили авылларында халыкка кино хезмәте күрсәтте. Үз эшен бик яратып башкарды, әтинең килүен авылларда көтеп алалар иде. Яшенле яңгыр киләме, көзге пычракмы, кышкы 30–40 градуслы салкынмы, күз ачкысыз буранмы – җәяүләп ерак юлларга чыгып китә иде. Ул вакытларда бит әле транспорт дигән нәрсә юк дәрәҗәдә. Сирәк-мирәк җигүле ат эләксә генә инде.

Бервакыт әти Кили авылыннан кино куеп кайтып килә. Килине чыгып әзрәк баргач, зират яныннан үтәргә кирәк. Зиратка килеп җитәрәк әти бер чардуган эчендә ут янганын күреп ала. Аптырап, куркып калса да, тәвәккәлләп китә бу зират эченә кереп. Теге ут чардуган эченнән чыгып, җиргә сикереп төшә һәм зират эченәрәк керә башлый. Әти курка-курка аңа иярә. Зиратның икенче ягына килеп чыкса, анда ашлык урлап маташалар. Ә берсе, фонарь яндырып, кеше куркытып йөри икән...

Тагын бер маҗара. 1952 елда әти Казанда киномеханик һөнәренә укый. Белем алып йөри торгач, акчасы бетә, ашарына калмый. Укытучысыннан сорап, авылга кайтып килергә уйлый. Товар вагоннарына утырып, ничек кирәк алай Шәмәрдәнгә кайтып җитә. Аннан җәяүләп 25–30 чакрым ераклыктагы Чапшарга кайтырга кирәк. Үч иткәндәй, кар ява башлый. Әти буранда адаша, хәле бетә, мүкәләп кайта башлый. Караса, алда бер кара нәрсә күренә. Минем сыман адашкан берәрсе үрмәләп килә икән, дип, әтинең эченә җылы йөгерә... Әмма теге карамчык бүре булып чыга! Бүре дә аның кырыеннан бара башлый. Бара торгач, тагын бер бүре килеп чыга.

– Ике ягымда – ике бүре, кайчакта улап та җибәрәләр, – дип искә ала иде әти.

Урман эченнән атлый торгач, урман кырыенда урнашкан колхоз умарталыгына килеп чыга. Анда ул вакытта Гани абый белән Нәфисҗамал апа (хәзерге вакытта Чапшарда яшәүче Мәрдәнов Габделбәр абыйның әти-әниләре) кыш көне дә шунда торып эшлиләр. Әти өй ишеген кага. Ишекне ачып җибәрсәләр, әтине күреп, аптырап калалар, чөнки аның бөтен җире, бите, күзләре бозланып каткан була. Алар аны ашаталар, җылыталар. Кортлыктан Чапшарга кадәр тагын дүрт километр кайтырга кирәк бит әле!.. Әти көч-хәл белән әнисе Фәризә янына кайтып егыла.

Икенче көнне әти яңадан Казанга кузгала. Әби аның юлына бер ипи тыга.

– Җәяүләп, Шәмәрдәнгә килеп җиткәнче ипине ашап бетергән идем инде! – дип искә ала иде әти. Сугыштан соңгы авыр, ачлык еллар була әле ул!

Нормабаш авылында кино күрсәткәч, әти бу авылда йокларга кала, икенче көнне велосипед белән кайтырга чыга. Нормабашны чыгып әзрәк баргач, урман кырыенда мунчала күле бар. Әти шунда су эчәргә төшә. Караса, кырыйда бер эт йөри. Эт дигәнең бүре булып чыга! Әти, велосипедына утырып, тизрәк Чапшарына элдертә.

Энем Мулланур армиядә хезмәт иткәндә, әти аңа үзенең фоторәсемен җибәргән булган. «Бу бит атаклы актер, клоун Юрий Никулинга охшаган», – дигән хезмәттәшләре.

Әйе, Юрий Никулин уйнаган кинофильмнарны карасам, әти искә төшә, бигрәк охшаш булганнар инде! Алар бер чорда яшәгәннәр шул, берсе уйнаган, икенчесе шуны халыкка кино итеп күрсәткән, туганнар диярсең!

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН


vk.com

Яшьлек хатирәләре

ҖЫРЛЫ АВЫЛ – ҖАЙЛЫ АВЫЛ

Яшьлегемдә миңа Татар Шатрашаны авылында балаларга белем бирү насыйп булды. Бик матур табигатьле авыл ул, халкы да мәрхәмәтле, тырыш. Татар Шатрашаны туган авылым Зур Чынлыдан шактый ук ераклыкта. Велосипед та, мотоцикллар да юк вакыт. Ерак араны, бернигә санамыйча, тәпиләп кенә җырлый-җырлый барып җитә идем. Укытучылар коллективы бик тату, бердәм булды. Ачык дәресләр үткәрү, клубта концерт-спектакльләр кую да гадәткә керде, ата-аналар белән дә бик тыгыз элемтәдә идек, авылдан киткәч тә элемтәләр өзелмәде, «Шатрашан укулары» бәйрәмендә очрашып сөйләшеп, фикерләшеп, истәлекләр яңарттык.

Хезмәт эшчәнлегенне башлаган авыл күңелгә бик якын, барысы да сагындыра. Сагынуым «Шатрашаным» дигән шигъри юлларга да күчте. Мин аңа көй дә яздым. Композитор Мәсгут абый Имашев нотага салды. Аңа олы рәхмәтемне җиткерәм.

Бер елны авыл бәйрәмендә шул җырны башкардым да. Ошаттылар. Укучыларым: «Якташыбыз җырчы Илсафка җибәрик әле», – дип сорап та алды. Илсаф аны шулай ук ошаткан иде, чираттагы концертында җырлады да. Шунда ук Шатрашан кияве Иршат Алмакаев та җырга яхшы мөнәсәбәтен белдерде һәм үзенең туган авылына да җыр язуымны сорады. Мин рәхәтләнеп елмайдым гына, шулай да тора-бара күңелдә хис бөреләнде, аннан чәчәк тә атты, җыр туды.

Һәр авылның җыры булсын иде ул. Бу – авылга хөрмәт, авыл халкын олылау билгесе дә.

Барис САБИРҖАНОВ.
Чүпрәле районы

САБЫРЛЫГЫ СОКЛАНДЫРДЫ

Әнкәемнең бакыйлыкка күчүенә инде 23 ел узса да, һәр хәрәкәте күз алдымда, әйткән сүзләре хәтердә. Әнкәй, колхозда эшләгәндә, төрле авырлыклар да кичерде, тән җәрәхәтләре дә алды. Трактор астында калып имгәнү, мотоциклдан егылып төшеп, бер кулының сеңерен өздерү, бозда таеп егылып, кулын сындыру дисеңме... Тома ятим үсүен дә ул яшерергә тырыша иде. Нинди генә авырлыклар күрсә дә, ул сабыр була белде. Чәпчемәде, берәүне дә гаепләмәде, күз яшьләрен дә күрсәтмәде. Бездә дә шул сыйфатларны тәрбияләргә тырышты, эшкә өйрәтте. Җәй көннәрендә колхозда өчәр гектар чөгендер утадык, утаган чүпне киптереп, кышка печән әзерли идек.

36 ел бергә гомер кичергән, дүрт баланы аякка бастырган, аларга яхшы тәрбия биргән җәмәгатем Нәкыя да бакыйлыкта инде. Ул да нәкъ әнием кебек сабыр холыклы, түзем, булганына шөкер итеп яшәүче иде. Икәү бергә хәзрәттән дини белем дә алдык, шуннан соң авылыбызда дини укулар да оештырдык. Әнием белән Нәкыямның балаларны тәрбияләүдә дә йогынтысы зур булды, балалар тырыш булып үстеләр, Алланың биргәненә шөкер. Яшьлек чоры уйландыра да, сокландыра да.

Рафис МӨХӘММӘТОВ.
Азнакай районы Әсәй авылы

Рәсми хәбәр

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Дачное авыл җирлегендә (кадастр кварталы номеры 16:16:214301) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 02.05.2023, № 923000089-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дачное авылы, Үзәк ур., 11 й. (телефон: +7 (84365) 78-3-33) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (Комплекслы кадастр эшләре заказчысының) (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 7 сентябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Биектау районы, Дачное авылы, Үзәк ур., 11 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 16 августыннан 2023 елның 7 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 7 сентябреннән 2023 елның 13 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Красносельское авыл җирлегендә (кадастр кварталы 16:16:221201) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 30.06.2023, № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Совет ур., 13 й. (телефон: +7 (84365) 2-35-85, 2-35-82) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (Комплекслы кадастр эшләре заказчысының) (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 7 сентябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе бистәсе, Совет ур., 13 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 16 августыннан 2023 елның 7 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 7 сентябреннән 2023 елның 13 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Семиозерка авыл җирлегендә (кадастр кварталы 16:16:213301) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 02.05.2023, № 923000089-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Биектау районы, Семиозерка авылы, Өске ур., 99А й. (телефон: +7 (84365) 3-29-63) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (Комплекслы кадастр эшләре заказчысының) (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 7 сентябрендә (9 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Биектау районы, Семиозерка авылы, Өске ур., 99А й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 16 августыннан 2023 елның 7 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 7 сентябреннән 2023 елның 13 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән муниципаль районы, Осиново авыл җирлегендә (кадастр кварталы номеры 16:20:080107) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 06.03.2023 ел, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Осиново авылы, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 1 й. (телефон: +7 (84371) 6-85-18) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы хакимиятенең (https://zelenodolsk.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 7 сентябрендә (14 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Яшел Үзән районы, Осиново бистәсе, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 1 й.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 16 августыннан 2023 елның 7 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 7 сентябреннән 2023 елның 13 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, «Малиновый овраг» СНТ (кадастр кварталы 16:16:081001) урнашкан күчемсез милек объектларына карата 06.03.2023, № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авылы, Юбилей ур., 1А й., 1000 бүлмә (телефон: +7 (84365) 74-7-79) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы хакимиятенең (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (https://rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 7 сентябрендә (15 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: ТР, Биектау районы, Биектау авылы, Юбилей ур., 1А й., 1000 бүлмә.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 16 августыннан 2023 елның 7 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 7 сентябреннән 2023 елның 13 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүмат сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Күзәту

БЕЗ һӘМ АЛАР

Хатын-кыз фикерләрен укый белмим, дип борчылма, син барыбер берни аңламас идең.

* * *

Егетемә алтын чылбыр бүләк итмәкче идем. Кайсы матур утырыр икән дип уйлап йөргәндә, башыма бәрде: егетем муенында утыручы иң матур бизәк үзем бит!

* * *

Егетем белән үбешкәндә, көзгегә күзем төште дә уйлап куйдым: мин – иң бәхетле кеше, чөнки бүген кашларымны 50% ташлама белән ясата алдым.

* * *

Егетем белән телефоннан сөйләшкәндә: «Синең белән талашырга вакытым юк, телефоным утыра», – дигән идем, иптәш кызым зарядка сузды.

* * *

Тормыш ул – иң кызыклы сериал. Менә быел 34 нче сезонны карыйм. Режиссер сюжетны ничек кенә бормалаган, әй.

* * *

Якшәмбе көнне егеткә кызы килә. Ә урта яшьтәге иргә – беренче гаиләдә туган малае.

vk.com

Хатирә

БӘХЕТЛЕМЕ КЕШЕ ДӨНЬЯДА?



vk.com

Филармониядә эшләгәннәргә һәм артистлар тирәсендә чуалырга яраткан бәндәләргә Сәүбән исеме яхшы таныш булырга тиеш. Ул озак еллар әлеге оешмада концертлар оештыручы – администратор булып эшләде. Башка хезмәттәшләреннән аермалы буларак, Сәүбән әфәнде филармония эшеннән бушаган араларда «левый» концертлар оештырырга да бик оста иде. Шуңа күрә дә артистлар арасында «Госконцерт», «Росконцерт», «Москонцерт»лар белән беррәттән «Сәүбәнконцерт» дигән төшенчә дә яшәп килде. Филармония бригадаларыннан аермалы буларак, мондый төркемнәр бишалты кешедән артмый, чөнки акча бүләсе бар, һәм аларда Ленин, партия турында җырлап, мактаулы исемнәр алган зур артистлар түгел, ә җитәкчелекнең игътибарыннан читтә калган, түбән хезмәт хакы белән рәнҗетелгән, ләкин тамашачылар арасында популяр булган иҗат әһелләре катнаша иде.

Шундыйларның берсе – Таһир Якупов. Җырчының сурәте төшкән, инде берничә тапкыр кулланышта булып таушалып беткән игълан кәгазен төштән соң гына элеп куйсалар да, кичкә авыл клубы шыгрым тула. Шуңа да Сәүбән абый оештырган «левак»ларда күп очракта Таһир була иде. Әлеге концертлардан артист бераз акча эшләп, матди хәлен җайлый, авыру әти-әнисенә ит, каз, бәрәңге кебек күчтәнәчләр алып кайтып, аларны сөендерә, ә администратор әфәнденең мөмкинлекләре зуррак. Ул рестораннарда кунак була, катер ала, җиңелчә генә мыскыл итеп, эшсез аптырап йөргән артистларны сыйлап, үзенә дан, шөһрәт казана. Акчалары булмаса да, рухи яктан бай, телгә оста сәнгать коллары мәҗлес барышында аны берсеннән-берсе уздырып мактыйлар, рәхмәтләр яудыралар һәм аларның да хезмәте эзсез калмый. Икенче көнне абзый чутыннан тагын шундыйрак мәҗлес оеша. Әлбәттә, мондый күңелле, гамьсез тормыш озак дәвам итә алмый. Баш төзәтергә дә рәте калмагач, Сәүбән финанс хәлен яхшырту турында уйланырга мәҗбүр була.

Әйе, Сәүбән Таһир белән кая гына барса да оттырышта калмаячагын яхшы аңлый, шулай да күп очракта аннан башка гына эшли. Сәбәбе – җырчының шаяру гадәте. Абзый бер генә минутка портфелен игътибарсыз калдырса да, аннан күпмедер тиен акча югала. Шуннан соң алар арасында мондыйрак диалог башлана.

– Таһир, Таһир, дим, бир акчаны.

– Күпме алганны әйтсәң бирәм.

Әлбәттә, тиен акчаны авырлыгы буенча гына чамалаган администратор бу сорауга җавап бирә алмый. Ул фәкать алга таба гына саклык чарасы күрә, бәдрәфтә утырганда да портфелен кочаклап утырырга мәҗбүр.

Шундый концертларның берсендә ни сәбәптәндер алып бару вазыйфасын Сәүбән әфәнде үзе башкарырга булган. Репертуарында берничә мәзәк, шаян шигырь булган администратор – конферанс портфелен сәхнә кырыена урындыкка куя да, артист хезмәтен башкару өчен, сәхнә уртасына чыгып баса.

– Нәби Дәүли. Бәхетлеме кеше дөньяда?

Кырын күзе белән генә сәхнә кырыена караса, портфель янында авызын ерып Таһир басып тора. Зал тулы халык булуына карап тормый, абзый җырчыга йодрык яный, ләкин моның файдасыз икәнен аңлагач, барып, портфелен ала да сәхнә аркылы гына йөгереп, икенче якка чыгарып куя. Ниһаять, тынычлап Нәби Дәүлинең фәлсәфи шигырен тамашачыга җиткерү нияте белән янәдән сәхнә уртасына чыга.

– Нәби Дәүли. Бәхетлеме кеше дөньяда?

Ирексездән күз карашы тагын акча тулы сумкага таба юнәлә. Ә анда Таһир «касса»ны ачып ук маташа. Әлбәттә, бу очракта чын актер булса, ул, һичшиксез, акчалы сумкасын гына түгел, бар дөньясын онытып яраткан хезмәтен башкарыр иде. Җырчының бу нахаллыгыннан Сәүбәннең төсе китә, сөйләшү сәләте югала, тик шулай да күпмедер мизгелдән соң ул аңына килә, кайда икәнлеген абайлап ала һәм, ашыга-ашыга, үзенең чыгышын кыскартып, халыкка Нәби Дәүли шигырен түгел, ә үз фикерен җиткерә.

– Юк, иптәшләр, бу дөньяда кеше бер дә бәхетле түгел.

Алга таба тамашаны чираттагы җырчы дәвам итә һәм бу кичә нәфис сүз, мәзәкләрдән башка гына үтеп китә. Алып баручының роле портфельдән ерак китмичә генә алдагы башкаручының исем-фамилиясен тамашачыга җиткерү белән чикләнә.

Нәҗип БӘДРЕТДИНОВ

Мач әйткән!

Стив ВОЗНЯК, айфон уйлап табучыларның берсе:

– Үзебез дә теләмәстән, без күзле кешеләрне сукырайттык.

Тарихи мизгел



vk.com

Дөньяның иң танылган актерларыннан саналган Жерар Депардье һәм Пьер Ришар. Узган гасырның 70 нче еллары.

Әз-мәз мәзәк

Доктор миңа тимер эчәргә кушты. Нервыларым тимер булсын өчен.

* * *

– Кайда мин? Кайсы гасырда? Ничә ел комада яттым?

– 8 сәгать йокладың, тор әйдә, эшкә соңга каласың!

* * *

Ял көнне рәхәт. Будильник куймыйча да иртәнге алтыда торып басасың.

МАТБУГАТ.РУ ТӨРТМӘЛӘРЕ

- Казанда ник бер чишмә дә юк? Казанны төзегәндә, асфальт астында калдырдылар микән? Әллә су сатучылар бетердеме? Ким дигәндә Казанның югары очында һәм түбән очында берәр чишмә булырга тиештер бит инде?
- Казан кибетләрендә өч пүлән утынны матур итеп бәйләп, 115 сумга саталар. Утынлыкка чыгып санап карагыз әле, сездә ничә сумлык тауар бар?
- Иң тиз узган вакыт – балыкта. Иң озак узган вакыт – көтүдә.
- Казан үзәгендә татар түбәтәе киеп йөргән кешене күрсәгез, ул турист булыр.
- Әби-бабай янында татар балалары гына түгел, рус балалары да тиешенчә сөйләшергә өйрәнә. Каникулдан кайткан бер малайдан: «Тебе сколько лет?» – дип сорагач, «Бог даст, шесть будет», – дип җавап биргән ди.
- Әле кайберәүләр ташкабакны сатып та ала. Шундый кешеләр дә бар.
- Казан кибетләрендә хәзер «хорошего дня» дип саубуллашалар. Шундый мода. Сез дә авыл кибетендә шулай саубуллашып карагыз, шаккатсыннар әле.
- Сөт әчемәсен өчен, аңа бака салганнар ди элек. Бакада нинди тылсым бар икән? Артык бака юкмы берәрегездә?
- «Бакчада кызынганны диңгездә кызынганнан аерам мин», – диде бер танышым. Болай булгач, бакча «загар»ы белән генә сезне алдап булмас, диңгезгә барырга туры килер.
- Әгәр авылда балалар гел бер җиргә килеп йөри икән, димәк, анда интернет тота.
- Эссе булса, эссе безгә. Салкын булса – салкын. Болытлы һава торышы булса, күңелсез – кояш юк.
- Казанда да бал кортлары оча. Алар балны кая алып кайтып тапшыра икән?
- Муеннарына электрон пропуск тагып йөрүче хезмәткәрләр эш белән богауланган кеше сыман тоела миңа.
- Арыш бар, бодай бар. Бутамагыз, казанлылар!

«Үпкәсез туй»

НУРЗАДӘ ҮТКӘРГӘН ТУЙ БӘБИ АШЫНА ӘЙЛӘНӘ ЯЗГАН

Җырчы Нурзадә җырчы гына түгел. Ул туйлар-мәҗлесләр дә алып бара (әле алып та кайта, дияр иде Алмаз Хәмзин). Берике кызыклы хатирәсен безгә дә сөйләде. Берзаман туй булырга тора. Тамада һәм команда, гадәттәгечә, иртәрәк килеп баса бит инде. Нурзадә дә шулай иткән. Әнә кияү белән кәләш тә килеп җитте. Абау! Ни бу? Кияүнең аягы гипсланган! Әмма, нишләмәк кирәк, аяк сынды дип, туйны күчереп булмый. Шунысы сокландыра: кияү дә, кәләш тә проблемага юмор белән генә караган. Берәү булса борчылыр иде, туй алдыннан аяк сындыруны әллә ниткән хәлләргә юрар иде. Ә болар көләләр генә: «Нурзадә, гафу ит, без бүген мондый аяк белән туй уеннарында катнаша алмабыз инде», – диләр.

Аяк сыну, татар әйтмешли, чепуха! Икенче туйда бер хатын бәбили үк башлаган. «Карыйм: кунаклар арасында авырлы ханым бар, – дип искә ала Нурзадә. – Моның вакыты җиткән бит инде, дип уйлап куйдым». Дәү әни әйтмешли, зрә уйлаган Нурзадә алай дип. Юрап китергән булса кирәк. Авырлы хатынның туйда ук тулгагы башлана. Тизрәк ашыгыч ярдәм машинасын чакырталар. Халык борчыла инде. Әмма туй бетәр алдыннан шатлыклы хәбәр килеп ирешә: теге хатынның исән-сау баласы туган! Кыз ягыннан туганнар саны ишәйгән булып чыга! «Бу хәлгә шактый еллар инде, әмма әле дә шундый җылы итеп искә алам ул туйны», – дип сөйләде «Ха-ха-ханә»гә Нурзадә.

Ир-атка ничек ишарә ясарга

1. **Турысын әйтегез.**
2. **Кычкырыбрак әйтегез.**
3. **Тагын да катырак.**
4. **Көн саен тукылдагыз.**
5. **Плакат ясап, каршына чыгыгыз.**

vk.com

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5129 данә
Гомуми тираж – 14057 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 315

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+